Мостай Кәрим

БЕЗНЕҢ ӨЙНЕҢ ЯМЕ

ТАТКНИГОИЗДАТ 1954

[illegible] – [illegible]
[illegible] [illegible] – [illegible] [illegible]
[illegible].
[illegible] – [illegible].

[illegible] 54

МОСТАЙ КӘРИМ

БЕЗНЕҢ ӨЙНЕҢ ЯМЕ

ТАТКНИГОИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ РЕДАКЦИЯСЕ
КАЗАН 1954

* * *

Редакторы
К. Г. Котдусова

Тышлык художнигы
Э. Е. Дъячкова

Художник *В. Горячев*
рәсемнәреннән копия

* * *

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

ӘНИЕМ КАЯ КИТТЕ?

Мөгаен, сезнең күңелегездә дә бик күп әйбәт нәрсәләр бардыр әле. Алар турында барлык яхшы кешеләргә сөйләп бирәсегез дә килә торгандыр.

Минем күңелемдә дә бар алар. Менә хәзер шуларны сөйли башлыйм.

Ул вакытта сугыш иде әле. Әтием барлык егетләр белән бергә фронтта фашистларны кыйнап йөри, ә әнием колхозда эшли иде. Бервакыт шулай әнием, колхоз председателе Якуп абыйның артлы чанасын җигеп, Тимертаудагы дәү әниемне кунакка алып кайтты. Дәү әни бер кич кунгач та, әни каядыр китәргә җыена башлады. Белəм инде, кеше еракка китәсе булмаса, сохари киптерми

ул. Минем әнием бер капчык сохари киптерде, башка тәмле әйберләр дә пешерде. Әллә ничә вак төенчек төенләде. Кеше бер дә юкка төенчек төенлимени? Миңа әлегә бернәрсә дә әйтмәгән булалар.

Беркөн таң белән мине дәү әни уята:

— Тор инде, Җәмил, тор, әнә әниең тәмле иттереп коймак пешергән,— ди.

Мин кинәт күзләремне ачам. Иң элек өстәл өстендә пары чыгып утырган самоварны күрәм. Әнием мич алдында пешеренеп йөри. Минем әнием буйга кечкенә булса да бик уңган ул.

Өстәлдә тәмлерәк аш булганда, минем ялындырып тора торган гадәтем юк. Тик андый аш бик еш эләкми шул. Тиз генә юынып, өстәл янында үз урыныма утырам. Ул арада әни дә, эшен бетереп, табынга килә. Дәү әни чәй ясый башлый. Тик чәй янына утыргач кына, табынның бик иртә әзерләнгәнен сизәм. Шунда ук әнинең капчыгын, төенчекләрен күреп алам... Берәү дә эндәшми. „Әһә,— дим мин эчтән генә,— барыбер беләм инде. Әни бүген каядыр китә“.

Чәйдән соң, әнием мине чакырып ала да аркамнан сөя:

— Җәмил улым, мин ерак шәһәргә барып кайтам, син дәү әниеңне тыңлап кына тор, яме,— ди.

— Я,—дип, мин баш селкеим. Үземнең күзләремнән яшь бөртекләре тәгәри. Барысын да алдан белеп тордым бит инде. Ә шулай да чыдап булмый. Минем елаганны күрмәмешкә салыналар. Мин борынымны бер-ике тартам да елаудан туктыйм.

— Алдыңны-артыңны карап йөре инде, кызым,— ди дәү әни,— юл газабы — җан газабы, дигәннәр бит.

Әни эндәшми. Бераздан соң ул чөйдәге тунын алып кия, ак калын шәлен бәйли. Дәү әни ана биштәрен кияргә булыша. Аннан без өчебез дә урындыкларга утырабыз. Дәү әни нәрсәдер укына, әни белән без тик кенә торабыз. Шуннан әни кинәт урыныннан тора, башта дәү әнине, аннан соң мине кочаклап ала.

— Исән-сау гына торыгыз инде,— дип пышылдый ул. Мин аны кызганып куйдым. Тышта кыш. Җитмәсә төн. Ә ул ерак юлга чыга. Әни тиз-тиз атлап ишеккә бара. Ул тагын безгә борылып карый да:

— Хушыгыз!— дип өй ишеген ача.

Менә ул өй алдына чыкты. Мин аның аяк тавышларын ишетәм: ул баскан саен кар шыгыр-шыгыр итеп китә. Әнием капканы ачып япты. Инде кар урамда шыгырдый. Тавыш ерагая һәм акрыная бара.

— Шыгыр... шыгыр... шыгыр...

Дәү әни белән икәү генә калабыз. Бераздан соң мин аннан:

— Дәү әни, җан газабы нәрсә ул?— дип сорыйм.

Дәү әни тирән сулыш алып куя да:

— Сез белмәсәгез иде инде, балакайлар, шул газапларны... Белмәсәгез дә, күрмәсәгез дә иде,— ди.

БАТЫРНЫҢ КЫЛЫЧЫ КАЙДА?

Без дәү әни белән һаман икәү генә торабыз.

Әнидән хат та, хәбәр дә юк,— дәү әни шулай ди. Мин инде аның ничә кич кунганын да оныттым. Әни киткәч, безнең сыер бозаулады. Теге, мөгезле кара сарыкның ике бәрәне булды: берсе ак, берсе кара. Бик салкын көннәрдә без бәрән-

нәрне өйгә алып керәбез. Бигрәк тиленләр әле, бернәрсә дә белмиләр алар. Я янып торган тимер мичкә бәрелеп сыртларын көйдереп китәләр, я сандык өстенә сикергән булып егылып төшәләр. Тамаклары туеп, җылынып алгач, бөтен өйне бер итеп, йөгерешеп уйныйлар.

— Әй, мәхлуклар, нинди рәхәтләнәләр,— ди дәү әни.

Ул, бияләй бәйләвеннән туктап, күзлекләре астыннан гына миңа карый (дәү әни „фронттагыларга" дип, гел бияләй бәйли). Мин ике итек кунычы арасына салынган күперемә чыралар тезеп утырам. Дәү әни шулай аз гына карап тора да яңадан кызу-кызу бәйләргә тотына. Үзе һаман сөйләнә:

— Күңелле шул аларга, икәү булгач... Менә синең дә туганың булса, нинди әйбәт булыр иде,— ди.

Мин, йөгереп килеп, дәү әнигә сыенам. Ул минем башымнан сыйпый.

— Фәритнең энесе бар, Маратның сеңелесе бар, барысының да инде... Минем генә беркемем дә юк,— дип, шунда ук борынымны тарта башлыйм.

— Синең сеңелең булса, яратыр идеңме?— дип сорый дәү әни.

— Би-и-к яратыр идем. О-о-о, сеңелем булсамы, мин аны күтәреп кенә йөртер идем. Бер дә екмас идем.

Дәү әни йомшак куллары белән битләремнән сөя. Сеңелем турында аны тагын, тагын сөйләтәсем килә минем. Ә ул башка бер сүз дә әйтми.

Мин яңадан күперем янына киләм. Бәрәннәр әллә кайчан күперемнең астын өскә китергәннәр инде. Бәрәннәргә рәхәт, алар икәү. Ә минем бер үземнең уйнасым да килми. Мин инде, сандык өстенә менеп, тик кенә утырып торам. Дәү әни әйткән сеңелем ничектер яныма ук килеп баскан төсле булып китә. Ул миңа шундый ачык күренә. Башта бик кечкенә төсле иде. Азрак торгач, ул Маратның сеңелесе Фәһимә кадәр була. Үзенең чәчләре кара, кызыл күлмәгенә ата каз күзе төсле түгәрәкләр төшкән... Көн буе мин аның турында гына уйлап йөрим.

Кич булгач, мин, дәү әнинең эше беткәнен көтеп, кроватьта бер үзем генә ятып торам. Кайсы вакытта шулай йоклап та китәм. Ә менә хәзер йоклап булмый. Тышта буран. Тәрәзә капкачларына җил китереп суга да, бөтен өй дөбердәп китә. Шушы буранда әтием дә, әнием дә өйдә юк. Алар, мөгаен, өшиләрдер әле. Ә сеңелем? Ул да әтием белән әнием янындадыр кебек тоела миңа.

Дәү әни самоварның суын түгеп, көлен кага. Бу эшен ул иң азактан эшли. Менә, утны сүндереп, ул да минем янга ята. Мин, юрган астыннан башымны чыгарып, аның колагына пышылдыйм.

— Дәү әни, дәү әнекәем, әкият сөйлә әле.

— Син һаман йокламадыңмыни әле, төн кошы?— ди ул.

— Берне генә, дәү әни... аннан йоклармын.

Кинәт тышта җил туктап калгандай була. Өйдә караңгы да, тын да. Мин яңадан юрган астына кереп китәм. Дәү әни ашыкмый гына сөйли башлый. Аның тавышы миңа юрган аша

әллә кайдан, җир астыннан килгән кебек, юк, җир астыннан түгел, борын-борын заманнан килгән кебек ишетелә.

— ... Борын-борын заманда,— ди дәү әни,— Тимербәк дигән батырның ай йөзле, йолдыз күзле Гөлнур исемле бик сылу сеңелесе булган. Тимербәк үзе илгә яу белән кергән адәм башлы, елан гәүдәле патшаның гаскәрләренә каршы сугышып йөри икән. Йорттагы барлык ирләр яуга каршы киткән булганнар, ди. Бервакыт Гөлнур үзенең дус кызлары белән күл буена суга төшкән, ди. Шулай бер чак тик торганда давыл күтәрелеп, өермә өерелә башлаган, ди. Кызлар барысы да камышлар арасына кереп посканнар. Өермә килгән дә, шул арада үтеп тә киткән. Кызлар йөгерешеп яңадан яр буена чыкканнар. Тик бер Гөлнур гына чыкмаган. Дуслары аны, бөтен күл буен бер итеп, кичкә кадәр эзләп йөргәннәр. Шул юктан юк булган да куйган, ди, ай йөзле, йолдыз күзле Гөлнур.

Яудагы батырлар, адәм башлы, елан гәүдәле патшаны җиңеп, куанышып илгә кайтканнар. Тик бер Тимербәкнең генә шатлыгы кайгы белән алмашынган. Батыр шул яудан кайтышлый ук, акбүз атыннан да төшмичә, бер селтәгәндә кырык чакрым җирне айкый торган кылычын кынына салып, Гөлнурны эзләргә киткән.

Ай йөргән, ди, ел йөргән, ди, батыр, җиде тауны үткән, җиде дәрьяны кичкән, ди. Бер заман тау куышында бәлтерәп беткән, чал чәчле картны очраткан, ди, Тимербәк.

— Сау гынамы, бабай? Нинди язмышлар китерде үзенне бу тау-ташлар арасына?— дип сораган.

— Юл кешесенә изге юл!— дип җавап биргән карт.— Син минем нинди юллар белән монда ки-

лүемне сорадың булса кирәк, егет. Мин дә син килгән юлдан килдем.

Тимербәк, атыннан төшеп, карт янына таш өстенә утырган. Карт яңадан сүз башлаган:

— Синең кебек егет чагымда минем сеңелемне аждаһа урлады. Шул заманнан бирле бердәнбер сеңелемне эзләп йөрим. Менә хәзер таптым мин аны. Шушы тауның артында аждаһаның алтын түбәле тимер сарае бар. Тик хәзер аждаһа белән алышырлык гайрәтем калмады шул минем, картайдым, йончыдым.

Тимербәк, кинәт урыныннан торып, аты янына йөгереп килгән.

— Минем сеңелем дә нәкъ шунда булырга тиеш. Әйдә, киттек, бабай. Без икебез дә бер үк нужа белән йөрибез икән, — дип, батыр өзәнгегә сикереп баскан.

— Сабыр ит әле, гайрәтле егет, — дигән карт. — Мин үзем дә яшь чагымда атаклы батырлардан идем. Бу аждаһага бик якын барып булмый. Ул үзенең сараена кеше килгәнен күрсә, кырык чакрымга ут чәчеп тора.

Шул вакыт Тимербәк, кыныннан алып, кылычын селтәп куя. Картның күз алдында җирдән күккә кадәр яшен сызылып үткәндәй була. Шуннан инде егет картка кылычның серен ача. „Бу кылыч, — ди егет, — үч кылычы“. Шуннан соң болар икәүләшеп юлга чыгалар. Көн үтәләр, төн үтәләр. Таң атуга инде карт батыр белән яшь батыр биек тауның башына менеп җитәләр. Тау башыннан болар ерактагы тимер сарайны күрәләр. Аның алтын түбәсе ялтырап тора. Ә сарайның тирә-ягы тоташ кара җир. Андагы бөтен нәрсә көл-күмергә әйләнгән. Бервакыт сарай эченнән йомгак кадәр генә ут тәгәрәп чыга. Ул йомгак якынайган саен зурая бара.

— Әнә, безне күреп аждаһа чыкты,—ди карт.— Мин бу утны бик күп тапкыр килеп карадым.

Батырлар янына ук килеп җиткәч, теге ут тоташ ялкынга әйләнә.

Тимербәк, кыныннан кылычын суырып ала да, сарай ягына карап селтәп җибәрә. Бер селти, ике селти, ә ут һаман көчәя генә бара. Бервакыт егет үзе бөтенләй ялкын эчендә кала, аның кашлары, керфекләре көеп бетә. Барыбер ул кылычын ташламый, селти дә селти: кылыч үзе дә уттай кызара. Көн сугышалар, төн сугышалар. Тик өченче көнне генә ут бераз басыла төшә. Тимербәк аждаһа сараена якынайганнан-якыная бара. Аның артыннан карт та ияртә. Кичкә таба ут бөтенләй сүнә. Тик җир өсте тәмам кара төтен була. Аждаһаның киселгән унике башы шулай төтәп ята икән.

Карт белән егет, аждаһа сараеның җиде кат ишеген җимереп, эчкә керәләр. Сарай эче тоткындагы кызлар, илнең иң матур кызлары белән туп-тулы була. Тимербәк белән бабай үз сеңелләрен эзләп табалар. Кызларның барысын да коткарып, алар туган илләренә кайтып китәләр... Ул куаналар, ди, ул көлешәләр, шатлыктан елашып та алалар, ди. Шатланмаслыкмыни?"

Дәү әни әкиятен гел шулай кырт кына бетерә. Мансур бабай кебек: „Әле дә череп-баеп гомер итәләр..." дигәнен бер дә әйтми.

Мин тын гына ятам. Ә күз алдымда, яшен кебек, кылыч ялтырап китә. Мин түзмим, дәү әнидән сорыйм:

— Шул батырның кылычы хәзер кайда икән, дәү әни?— дим мин.

Дәү әни ашыкмыйча гына җавап бирә:

— Әтиең кулында, балам, хәзер ул кылыч. Йокла инде...

ТАНЫП БУЛМЫЙ ТОРГАН ЯЗУ

Әнием кайтмый да кайтмый...

Беркөн иртән, дәү әни сыер саварга чыккач, хатлар, газеталар ташучы Гөлсылу апа килеп керде. Әнигә Уфадан килә торган газетаны калдырды. Мин ул газетаның зур итеп язылган ике сүзен генә таныйм, аны „Кызыл Башкортстан“ дип көн дә кычкырып укып куям. Гөлсылу апа дүрткә бөкләнгән тагын бер кәгазь кисәге дә бирде. „Монысы әниеңнән телеграмма“,— диде дә чыгып китте. Мин кулыма телеграмманы тотып карадым да калдым. Нәрсә икән ул телеграмма? Яхшы әйберме икән, әллә начармы икән?

Мин дәү әниемнең каршына йөгереп чыктым. „Дәү әни, дәү әни...— дидем,— телеграмма китерде!“

— Кем диден? Кайда соң ул?— дәү әни якягына карана.

Мин кулымдагы кәгазьне ана бирәм. Анын куллары калтырап китә:

— Ходаем, пахарун гына булмаса ярар иде,— ди.

— Юк, дәү әни, пахарун димәде Гөлсылу апа. „Әниеңнән телеграмма“,— диде.

Дәү әни мине, тиз генә киендереп, Мансур бабайны алырга җибәрә. Без, бер-бер хәл булса, киңәшкә гел аны чакырабыз. Ул ничек әйтсә, шулай эшлибез. Анын дөньяда белмәгән нәрсәсе юк.

Мансур бабайлар безнең күршедә генә торалар. Ул: „Инде туксанга житеп барам“,— ди. Туксан бик күп була ул, мин туксанга кадәр саный беләм. Ул чакта әле Мансур бабайның Фәрхениса әби исемле сукыр карчыгы бар иде. Хәзер инде ул сукыр түгел: сугыш беткәч, Ман-

сур бабай аны Уфага алып барды да күзләрен төзәттереп кайтты. „Харап әйбәт күрәм инде“,— ди Фәрхениса әби хәзер. Ә элек ул сукыр иде.

Мансур бабайның өендә — шул әби дә үзе генә. Уллары булмаган, ә кызлары чит авылга китеп беткән. „Кодрәт белән генә торгандай торасың инде, Мансур абзый“,— ди аңа дәү әни. „Колхоз карамаса, кодрәт белән генә әллә кая барып булмас иде, карендәш“,— ди ул. Мин алар сөйләшкәнне кайчакта аңлап та бетермим.

Мин, ике арадагы капкадан гына чыгып, Мансур бабайларның өй алдына кердем. Ул ишек алдын себерә иде.

— Бабай! Телеграмма китерделәр, дәү әнием сине чакырды, хәзер үк,— дип кычкырдым мин.

Бабай сорашып-нитеп тормады, өенә кереп китте. Мин болдыр янындагы кар өеменнән бер тапкыр гына аяк белән шуып төштем дә кайтып киттем.

Мансур бабай безгә киңәш бирергә килгәндә һәрвакыт ак чикмәнен киеп, кызыллы-күкле матур билбавын буып килә. Кайвакытта Фәрхениса әбине дә ияртә. Хәзер дә шулай икәү җитәкләшеп килеп керделәр.

— Исән генәме, сау гынамы, карендәш?— ди ул һәм әбине җитәкләп сандык өстенә китереп утырта.

— Телеграмма дип сөйләндеме Җәмил, каян килгән, кемнән?

— Көнбикәдән ди дә бит, нәрсә икәнен генә белеп булмый шул,— дип пошына дәү әни.

— Кая, бир әле монда,— дип, бабай кәгазьне ала.— Телеграмма ни инде ул, карендәш, тимер чыбык буенча җибәрелгән хат була. Күрәсең, Көнбикә суккандыр,— ул кәгазьне озак итеп, әйләндергәләп карап тора.

— Укыр идең, ичмасам, абзый... Пахарун гына булмаса ярар иде дип йөрәгем купты. Сугышта балалар бик күп бит.

— Пахарун түгелен ачык беләм, карендәш, менә тик укып бирүне булдыра алмыйм. Заманында өйрәнмәгән һөнәрен, йөремәгән җирен калдырмадым. Ырымбурында дисеңме, Стәрлесендә дисеңме,— барысында да булдым. Сөйләп торасы да юк инде. Ә менә шул язу танырга өйрәнеп булмады.

Дәү әни кәгазьне яңадан үзенә ала, күзлеген бер киеп, бер салып, язуны укымакчы итә.

— Пошынма, кодагый,— дип сүзгә кушыла Фәрхенисса әби. Күзе күрмәгәч, ул бик сирәк сөйләшә.— Көнбикәдән булгач, әйбәт нәрсәдер әле.

— Фәрхенисса күзләре күрмәгәнгә сукыр,— ди дәү әни,— ә без синең белән күзле була торып дөм сукырбыз, абзый. Әрнеп куям. Әнә, колхоз төзегән елны өйрәтергә әйткәндә, „шайтан сабагы“ дип, йөремәдем бит. Менә хәзер дивана кебек утыр инде. Укый-яза белсәм, улларыма үз фатихаларымны үзем язып җибәрер идем.

Картаеп беткән өч кешенең шулай аптырап торуыннан миңа бик кыен булып китә. Иөгереп барып, шушы язуны кычкырып укып бирәсем килә. Ничек куанырлар иде алар. Нигә мин әле җиде белән генә барам икән, нигә сигез белән бармыйм икән. Шушы минутта ук минем мәктәпкә китеп, язу өйрәнеп кайтасым килә. Барыбер өйрәнермен мин ул язуны. Әнием кебек, калын-калын китаплар да укырмын әле, башта бөтен әкиятләрне дә укып бетергәч...

Фәрхенисса әби яңадан эндәшә:

— Кодагый, урамнан балалар шаулашып үтеп бара түгелме? Берәрсен чакырып кертер идең дә укытыр идең шул кәгазьне.

Дәү әнинең йөзе яктырып китә:

— Бәй, балалар бар чакта, ни эшләп аптырап торабыз әле? Исемә дә килмәгән... Ул башта, тәрәзәгә килеп, урамга карый, аннан шәлен генә ябынып чыгып китә.

Дәү әнием югары оч Мәхмүтне ияртеп керә. Мин беләм, ул быел бишенчедә укый.

— Улым, шушы кәгазьне генә укып бирче, бүген Гөлсылу китереп киткән,— ди дәү әни.

Сынап торам. Мәхмүт эреләнеп кенә язуны ала.

— Көнбикә ападан телеграмма бу. Русча язылган.

— Ул кадәрен белдек тә аның белүен,— ди Мансур бабай.

— Укы, улым, укы.

Мәхмүт башта язуны русча укып чыга. Аннан башкортча сөйләп бирә:

— Көнбикә апа әйткән: „Уналтысында кайтып төшәбез,— дигән,— станциягә ат җибәрсеннәр,— дигән,— сәлам“,— дигән.

Дәү әнием үрсәләнеп арлы-бирле йөри башлый.

— Чишенегез, абзый, я кодагый, нәрсә эшләп утырасың, чишен. Чәй эчеп алырбыз,— ул кинәт туктап кала.— Бүген ничәсе соң әле?

— Бүген унбише инде, иртәгә уналтысы... Башка нәрсә әйтмәгән, шул, — ди дә Мәхмүт чыга башлый.

— Утыр, улым, син дә утыр,— ди дәү әни,— баллап чәй эчәрбез.

— Рәхмәт, әби, мәктәпкә барам,— дип Мәхмүт чыгып китә.

Минем Мәхмүткә күзем кызып кала. Нинди бит, тотлыгып та тормады, чатнатып укыды да бирде! Җитмәсә, чәй дә эчмәгән була.

Мансур бабай белән Фәрхениса әби, чишенеп, өстәл янына килеп утыралар.

Теге телеграмманы мин әле яңа гына аңлап алам: иртәгә минем әнием кайта. Ул әле кайда икән? Нигә бүген үк уналтысы түгел икән? Миңа ул, шыгыр-шыгыр басып, капкадан кергән кебек була. Әнине бигрәк күрәсем килде шул минем...

Кинәт дәү әни радионы борып җибәрде.

— Әллә ниткән гадәтең шул, карендәш, үзең урысча бернәрсә дә төшенмисең, үзең көн буе шул радионы сөйләтәсең, — ди Мансур бабай.— Ничә керсәм дә, тик тормый.

— Москва үзе сөйли бит, абзый. Өеңдә Москва тавышы ишетелеп торгач, күңелгә рәхәт, — ди дәү әни. — Аңламасам да, мин аның өметле сүз сөйләгәнен беләм бит. Син алай димә,— ул шаулап торган самоварны, өстендәге көлен өреп төшерде дә, өстәлгә китереп куйды.

Менә эчәләр инде хәзер чәйне болар, бер башлагач...

МЕНӘ КЕМ ИКӘН МИНЕМ СЕҢЕЛЕМ

Председатель Якуп абыйның артлы чанасы безнең капка төбенә килеп туктады. Без дәү әни белән икебез дә тәрәзәгә килеп капландык. Башта кучерга утырган толыплы берәү сикереп төште. Монысын таныйм: бригадир Бадамша

бабай. Аннан әниемнең ак шәле күренеп калды. Ул арада дәү әни чыгып та йөгерде. Мин сикереп идәнгә төштем. Бер киез итегемне шунда ук таптым, ә икенчесе юк та юк. Итек мин эзләгән саен ераграк кача ахры.

Менә капка ачыла. Мин яңадан сандык өстенә сикереп менәм дә тәрәзәгә капланам. Әнә әнием, әнекәем кайтып керде. Әнием, әнекәем... Ә нинди кечкенә кызны җитәкләгән соң ул? Дәү әни ул кызны күтәреп ала. Башкача түзеп булмый. Сандык өстеннән сикереп төшәм дә, шул бер итегемне генә кигән көе, тышка йөгерәм. Болдырга чыгып та җитәм — әнием мине кочаклап та ала. „Тиле, — ди әни, — яланаяк чыгалармыни?" Аның тавышын ишеткәч, тагын да күңелем тулып китә. Мин эндәшмим, әнинең карлы шәленә битемне куеп, аның муеныннан кысыпкысып кочаклыйм.

Өйгә кергәч, теге кечкенә кыз белән мине кара-каршы китереп бастырып куялар.

— Менә сеңелеңне алып кайттым, Җәмил, Оксана исемле, чишендер өстен, — ди әни.

Миңа бик күңелле булып китте. Башта мин Оксананың муеныннан кочаклап алдым, аннан битләрен сыйпадым. Минем дә сеңелем бар, Оксана исемле сеңелем бар! Сеңелемне күтәреп алырга да телим, тик көчем генә җитми.

— Күтәрмә, Җәмил, ул зур бит инде. Ычкындыр төймәләрен. — Дәү әни минем башымнан сыйпый. Әнием белән алар безгә көлеп карап торалар.

Мин башта сеңелемнең пальтосын, аннан башлыгын салдырам.

Оксананың чәчләре кара түгел, коңгырт, күлмәгенә ата каз күзе төсле түгәрәкләр дә төшмәгән, кызыл канатлы күбәләкләр төшкән. Ә буйга Фәһимәдән дә зур. Минем чаклы. Исеме дә

урамында бер исем — Оксана, нинди матур! Ә нигә соң ул эндәшми, турсаеп тора?

— Әни, Оксана да эндәшсен әле миңа. Абый, дисен.

— Ул әле өшегән, улым, җылынгач барын да әйтер, яме.

— Я.

Мин сеңелемне, кулыннан җитәкләп, сандык янына алып киләм. Шунда ук кровать астына кереп, үземнең бөтен уенчыкларым салынган тартманы алып чыгам. Минем әйберләрем байтак кына. Таш атым, агач мылтыгым, кечкенә арбам, бака кабырчыкларым, имән чикләвекләре, тәти ташларым, матур-матур сурәтләр төшкән кәгазьләрем бар. Шәһәрдәге Сылу апа алып килгән кызыллы-яшелле тутый кошым белән тимер саплы пәкем дә югалмаган иде әле ул чакта. Тимер саплы пәкемнең Марат кына былтыр урманда башына җитте инде, — кипкән шома көпшәдән сыбызгы ясаганда.

Минә никадәр уенчыгым бар иде минем. Шуларның барысын да мин Оксана алдына тезеп куйдым.

— Ал, ал, Оксана, — дим мин, — барысын да сиңа бирәм. Җәй булгач, мин тагын бик күп матур нәрсәләр җыярмын әле.

Оксана ояла. Нигә ояла ул? Мин әнием белән дәү әниемә карыйм. Алар икесе дә мич каршысындагы скамьяда елмаешып утыралар. Әнием, безнең янга килеп, икебезне дә сөеп ала. Нинди шат минем әнием! Әнием шат чакта миңа бик рәхәт була. Сезгә дә шулайдыр инде ул.

— Уйнагыз, күгәрченнәрем, уйнагыз, — ди әни.

Мин бер үзем генә чакта ул „күгәрченем“ дими иде. Хәзер икәүгә күрә шулай әйтәдер инде. Күгәрчен ялгыз булмый торгандыр шул. Әнә бит,

безнең келәт кыегына оялаган күгәрченнәр дә никадәр. „Тату кошлар алар, күгәрченнәр, гөрләшеп кенә торалар“, — ди Мансур бабай.

Әнием сөйгәч, Оксана көлеп җибәрде. Ул башта кулын әкрен генә тартмага сузып, бака кабырчыгын тотып-тотып карады, аннан соң имән чикләвекләрен алды. Иң азактан гына теге кызыллы-яшелле тутый кошның койрыгыннан тотып, селкетеп карады. Ләкин ул шалтырамый иде шул хәзер. Мин аның эчен тишеп, вак кына ташларын коеп бетергән идем инде. Сеңелем миңа нәрсәдер әйткәндәй булды. Мин аңламадым. — „Нәрсә дидең, Оксана, нәрсә дидең?“ — дип сорасам да, ул кабат эндәшмәде. Зәңгәр күзләрен зур ачып миңа карап торды.

Әни минем яныма килеп утырды.

— Җәмил, — диде ул, — синең сеңелең бит бик ерак шәһәрдә торды. Ул шәһәрдә безнеңчә сөйләшмиләр. Әлегә Оксана да башкортча белми. Син аны өйрәтерсең, яме?

Мин әнинең сүзләрен аңлап бетермәсәм дә, ярар, дим. Ә нигә ул шәһәрдә башкортча сөйләшмиләр? Ничек сөйләшәләр соң анда? Еракмы икән ул шәһәр? — шуларны әниемнән сорашасым килә. Сорашыр нәрсәләр тагын да күп әле.

Кинәт сеңелем әниемә килеп сыена. Әллә миннән куркамы икән?

— Әни, әйт Оксанага, мин аңа тимим бит. Мин аңа бер дә тимим, ә, әни... — дим мин. Әнием читкә борыла. Ул күңеле тулганда гел шулай итә...

— Ягез, кунаклар, иркенләп чәй эчеп алыйк, — ди дәү әни, — самовар суына.

Мине Оксана белән иң түрдәге урынга янәшә утырталар. Шунда мин үземнең кечкенә чынаягымны бөтенләйгә сеңелемә бирдем. Әйе, бөтенләйгә шул.

Азрак торгач та, безгә Мансур бабай белән Фәрхениса әби керде. Бабай, әбине җитәкләп, сөйләнә-сөйләнә түргә узды: „Алтыдагы сәфәрдән кайтса, — ди ул, — алтмыштагы күрергә килсен, дигәннәр борынгылар“. Алар артыннан ук Шаһит абыйлар, Сәгыйдәләр килде. Бөтен урам килде ул көнне безгә. Һәр кеше Оксананы я күтәреп ала, я болай гына сөеп куя.

— Менә Җәмилнең дә сеңелесе булды. Нинди матур бала, — диде Миңлекәй әби, — бәхете-тәүфигы булсын инде.

Үзе безнең икебезгә дә берәр уч шомырт бирде. Бадамша бабай Тәзкирәсе Оксанага курчак китерде, курчагы бигрәк матур инде: күлмәк кигән, яулык бәйләгән, чын курчак. Оксанага бик ошады, әллә ничә рәт сикереп тә алды ул аны. Кичкә кадәр кешеләр килделәр дә килделәр. Өйдә күмәк чакта миңа бик рәхәт була ул, сезгә дә шулайдыр инде.

Кешеләр таралышып беттеләр. Мин әнинең итәгендә утырам. Ә дәү әни Оксананың чәчен тарый. „Кызымның чәчләре керләнгән, иртәгә үк мунча ягарга кирәк“, — ди ул. Минем Оксанага бик күп сүзләр әйтәсем килә. Тик ничек кенә дип эндәшергә икән сеңелемә. Ул бит барыбер минем сүзләремне аңламый. Нигә генә аңламый икән инде? Башта туганым юк иде. Хәзер туганым бар да бит, минем белән сөйләшә генә белми. Мин кычкырып елардай булдым.

Үзем һаман аңа карыйм.

— Җәмил... — диде ул. Мин сискәнеп киттем. Әзрәк торгач, өстәп куйды:

— Абый... — нинди матур итеп әйтә ул.

— Оксана! Туганым! — дим мин. Әниемнең итәгеннән сикереп төшәм дә аның битен сыйпыйм. — Әйт, тагын әйт.

Ул эндәшми. Үзе елмая.

— Кош та бит сайрарга әкренләп өйрәнә. Ул да өйрәнер, балакай, — ди дәү әни.

Караңгы төшкәч тә, Оксананың йокысы килде. Әнием скамья янындагы утыргычларны тезеп куйды да аңа урын җәйде. „Бүгенгә монда ятып торсын да, иртәгә аның үз кроватен кертербез“, — диде ул дәү әнигә.

Оксана яткач ук йоклап китте. Ә мин аның янына утырдым да тик кенә карап тордым. Аннан соң Оксананың мендәр читенә башымны тидереп карадым... Тик әнием мине күтәреп алганда гына күзем азрак ачылып китте...

ОКСАНА КУРКА

Дәү әнием әллә кайчан инде Тимертауга кайтып китте. Без өйдә өчәү генә калдык: мин, әнием һәм Оксана. Әни көн буе колхоз келәтендә бодай чистарта. Ул бодайларны, яз булгач, җиргә чәчәләр. Әнием дә бодайны машина белән чәчә белә. Без быел, малайлар белән якын басуга барып, бодай чәчкәнне үзебез карап тордык. Ат җиксәләр — бер машинага икене җигәләр. Ә трактор булса — әллә ничә машинага бер генә тракторны җигәләр. Якын басуда үзебез күрдек.

Әнием көндез кайтып безгә аш пешереп ашата да тагын китә. Оксана белән без икәүләп өйдә калабыз. Без дә тик кенә тормыйбыз: идән себерәбез, чынаякларны юабыз. Сеңелем хәзер оялмый. Минем белән сөйләшергә дә өйрәнде. Башта кыен иде дә, хәзер ансат инде. Мин аңа бозауларның, кышлау гөлләрнең, бәрәннәрнең, кошларның, — бөтен-бөтен нәрсәләрнең исемнәрен өйрәттем. Элек ул очраган бер әйберне: „Бу

нәрсә? Бу нәрсә?“ дип сорап кына тора иде. Ә хәзер үзе дә белә.

Җылы көннәр булса, Фәритләр, Маратлар, Фәһимәләр белән бергә тау шуарга да йөрибез. Хәзер көннәр җылынды инде. Күптән түгел әниләрнең март бәйрәме дә булды. „Тиздән яз килер инде“,—диләр зур малайлар.

Кайсы чакта әнием безне Маратларга илтеп куя. Аның Фәһимә исемле сеңелесе дә бар дигән идем бит. Аларда без дүртәүләшеп „күз бәйләш“ уйныйбыз. „Акрынрак басып йөрегез, таш табаннар!“—ди безгә Маратның дәү әнисе. Ул минем дәү әнием кебек түгел, бер дә тавышны яратмый. Әллә башы авырта инде.

Оксана белән Фәһимә дуслашып киттеләр. Марат белән мин былтыр ук дус булып алгач, сеңелләребез тик йөресенмени? Без аларның кулларын тотыныштырдык та бер-берсенә өчәр тапкыр „Дусмы?“—„Дус!“ дип әйттердек. Безнең урамда бөтен малайлар да, кызлар да дуслашканда шулай итәләр.

Беркөнне шулай, әнием төшкә кайтып киткәч, тышта бик яман җил күтәрелде. Мин җилнең нинди леген, бакчаның ерак почмагындагы каенга карап беләм—ул тәрәзәдән күренеп тора. Тышта давыл купса, каен очып китәрдәй булып чайкала башлый. Аның шәрә, нечкә ботаклары, бөгелеп-бөгелеп, безнең урам як коймага сугылалар. Шундый чакта каен миңа бик газаплана төсле күренә. Нигә исә икән инде ул җил? Нигә өзгәли икән каенны?

Без, Оксана белән икәү, тәрәзәдән бакчага карап утырабыз. Мансур бабайларның морҗасыннан соры төтен чыга да безнең бакчага егылып төшә. Ул әллә каенны җылытырга телиме икән?

Мин әллә кайчаннан бирле саклап килгән серемне Оксанага ачам. Мин аны кар эрегәч кенә әйтермен дигән идем дә, түзеп булмый бит:

— Яз булгач та, Оксана, мин сиңа бер сарай хәзинә бүләк итәм,— дим.

Сеңелем аңламый тора. Аның әле хәзинә күргәне юктыр шул. Мин аңа сөйләп бирәм.

— Әнә, бакчаны күрәсеңме? Ул мондый гына бакча түгел, анда алтын яфраклы көмеш агачлар үсә. Таңнан алып төнгә, төннән алып таңга кадәр төрле-төрле кошлар сайрый. Чәчәкләрдән нур тамып тора, дим. Шундагы бөтен агачлар арасында бер каен бар, каен төбендә таштан салынган сарай, сарай эчендә бер әкият малаеның хәзинәсе бар. Хәзинә—уенчык дигән сүз ул. Шул малай, җәй булгач, бер кечкенә генә әкият кызын бакчага алып керер дә каен төбенә алып килер. Сарайның таш ишеген ачар да болай дип әйтер: „Менә, сеңелем, шушы сарайда нәрсә бар,— шуның барысы да синеке. Уйна, шатлан, кайгы күрмә“.

— Кирәкми, бу әкият булмасын, чын булсын,— ди Оксана.

— Юләр,— дим мин,— малае бит аның Җәмил исемле, ә кызы Оксана исемле була.

Шулай дигәч сеңелем көлеп җибәрде:

— Тагын сөйлә, Җәмил.

— Ә аннан соң,— дим мин,— без анда кечкенә флаглар кадап куярбыз да, җәй көне Көмешле елгасы буенда булган кебек, пионерлар лагере ясарбыз. Фәритләр, Маратлар, Фәһимәләр килер. Җыр җырларбыз. Әйдә, хәзер үк җырлап карыйк.

„Әйдә“,—ди Оксана.

Без икебез дә җырлый башлыйбыз:

Яз килер, яз килер.
Кар эрер, кар эрер,
Үләннәр үсәрләр,
Үләннәр үсәрләр,
Бакчага керербез,
Җырлашып йөрербез,
Флаглар кадарбыз,
Лагерьлар ясарбыз...

— Тик кошларны куркытмабыз, яме,— ди Оксана, җырдан туктап.— Алар матур сайрап торырлар.

— Таш та ыргытмабыз, „кө-ө-ө-ш!“ дип тә кычкырмабыз, Оксана, әйе бит. Тилгәнне генә куарбыз. Югыйсә ул чебешләрне урлый.

Кинәт көчле җил тәрәзә капкачларына китереп сукты. Алар дөбердәп киттеләр. Оксана „Ой!“ дип каты кычкырып җибәрде. Мин сеңелемә әйләнеп карадым, аның күзләре зур булып ачылганнар. Алар миңа бу юлы ачык зәңгәр булып түгел, карасу булып күренделәр. Нигә алай иреннәре еларга теләгән кебек дерелдәп тора? Нәрсә булган аңа? Шул арада тәрәзә капкачлары тагын да шәбрәк дөбердәп куйды. Оксана инде кровать өстенә өелгән мендәрләр артына ук кереп качты. Мин аптырап урамга карадым Анда караңгы төшеп килә. Җил һаман безнең каеннын ботакларын тарткалый. Ә ишек алдында элеккечә беркем дә юк. Тик Сәгыйдә апаларның ала эте генә киртә буендагы сырынты өстендә аунап ята. Нәрсәдән курка соң сеңелем? Мин дә аның янына килеп мендәргә сыендым.

Оксана, ике уч төбе белән колакларын басып тоткан да, бөршәеп утырып тора. Ул, калтырана-калтырана, миңа пышылдый:

— Кач тизрәк, Җәмил, кач, әнә фашист килгән тышта. Ишетәсеңме, мылтык ата. Ул усал. Кач тизрәк!

Мин дә куркып киткәндәй булдым. Тышта караңгы. Җил һаман тәрәзә капкачларын селкетә. Әнием дә өйдә юк... Ә фашист ерак ул, анысын яхшы беләм. Шулай да мин тиз генә сикереп төшәм дә тартмадан агач мылтыгымны алып киләм.

— Күрәсеңме моны,— дим мин Оксанага,— килеп кенә карасын фашист. Кирәген алыр. Әтиләр фронтта булгач, килә аламы соң әле ул монда?.. Курыкма, Оксана, курыкма!

— Ә кем ата соң анда?

— Җил ул, җил. Тәрәзә капкачлары элек тә дөберди иде. Якты чакта ишетмәгәнсең генә син аны.

Ул инде колакларын куллары белән капламый. Без икәүләп мендәрләр артында, кроватьның аргы башына аркаларыбызны сөяп, утырып торабыз.

— Беләсеңме, Оксана,— дим,— мин бар чакта, син курыкма. Мин, үсеп, Тимербәк батыр булгач, фашистларны җиңәргә китәм, син өйдә каларсың. Мин кайтканчы сине аждаһа урлап китсә дә, мин сине барыбер табып коткарырмын. Син курыкма, яме...

— Ой, кирәкми, кирәкми. Син беркая да китмә!.. Ә аждаһа нәрсә ул?

— Би-и-и-к зур елан.

— Ә елан нәрсә?

— Еланмы. Елан ул чага, тешләп ала.

— Куй, тешләмәсен, мин куркам.

— Юләр син, Оксана, мин бит аны җиңәм, кылыч белән.

— Мин куркам, я ул ашар.

— Юк, аждаһа ашамый ул. Соры бүре генә ашый, кызыл такыялы кызны ашаган кебек. Сине бүре ашаса, мин аның корсагын ярып җибәрермен, о, мин ул бүрене!..

Оксана миңа сыенганнан сыена бара. Үзе дер-дер калтырый. Өйдә бөтенләй караңгы төште. Тик ишек ягындагы мич кенә агарып тора.

— Тыңлагыз! Уфа сөйли...

Бу безнең радио сөйли башлады.

Дәү әни әйткәндәй, рәхәт булып китте. Мин инде, мендәр артыннан чыгып, яңадан тәрәзә янына килеп бастым. Менә урам капкасы ачылды. Берәү йөгерә-йөгерә болдырга таба килә. Бу әнием булырга тиеш. Капкадан кергәч ул гына шулай йөгерә.

СЕҢЕЛЕМНЕҢ ТӨШЕ

Мин яз булганны бик яратам. Оксана да ярата. Сез дә шулайдыр әле. Бәрәннәр нәрсә эшли соң, бәрәннәр? Карагыз әле, карагыз. Ничек рәхәтләнеп йөгерешәләр, сикерешәләр! Агы нигез буенда нәрсәдер иснәнеп йөргән була. Аның кечкенә генә койрыгы бертуктаусыз кыймылдап тора. Ә карасы болдырга менә дә сикереп төшә. Аның уены шул. Бераздан соң инде икесе өйнең ике почмагына таба йөгереп китәләр дә шуннан килеп маңгайлары белән сөзешәләр. Ызгышып түгел, болай шаярып кына шулай итәләр алар. „Мөгезләре кычыта сабыйларның“,— ди Мансур бабай. Бәрән сабый була диме икән? Мансур бабай кечкенә балаларны гына түгел, колыннарны, бәрәннәрне, этләрне — бөтен хайваннарны да бик ярата шул. Шуның өчен бәрәннәрне „сабыйлар“ дип әйтә дә ул. Яман кешеләр белән фашистларны гына яратмый безнең Мансур бабай. Үзе шулай ди.

Әнием ерак шәһәргә киткәч туган алалы-колалы бозау да хәзер бик зур үсте инде. Ул бер-

үзе бакча буенда уйнап тик йөри. Ата каз белән ана каз үзләренең сары йомгаклар төсле бәп-бәләкәй генә балаларына, нәрсәдер сөйли-сөйли, өй алдын күрсәтеп йөриләр. Ул бәбкәләр әле бүген генә ишек алдына чыктылар. Әнием өйдә чакта без аларны тотып-тотып караганыбыз бар. Оксана әле берсенә су да эчерде.

Монысын үзегезгә генә әйтәм. Каз бәбкәләренең бер иң матурына мин „Оксана“ дип исем куштым. Эчемнән генә. Ул бәбкәне мин ерактан да таныйм. Әнә хәзер ул кечкенә генә таш өстенә менеп баскан да, муенын әле бер якка, әле икенче якка борып, җылынып тора.

Ә тавыклар соң, тазыклар. Алар, бөтен тирәякны бер итеп, җырлап йөриләр. Нинди күңелле, җирдә яз булгач! Барысы да шат, барысы да уйный, барысы да җырлый.

Оксана белән без икәүләп бакча буендагы бүрәнәләр өстенә менеп утырганбыз. Бу бүрәнәләрдән Якын басу күренеп тора. Басуда безнең әни машина белән бодай чәчеп йөри.

— Ән-ә, Җәмил, алдагы тракторның чәчкеченә баскан, шул әнидер әле,— ди Оксана.

Мин аңа таба әйләнеп карыйм. Сеңелемнең зәңгәр күзләре тагын да яктырып киткән кебек була. Аның борын өстендәге вак кына сипкелләре, кояш нурларында ялтырап, җемелдәгәндәй күренәләр. Мин Оксанага тагын да сыеныбрак утырам.

— Оксана,— дим мин,— әйдә җитәкләшеп утырабыз.— Сеңелем шунда ук миңа кулын суза. Мин аны җитәкләп алам. Әни дә безне күреп торадыр әле. „Әнә, минем балаларым кая менеп утырганнар!“— дидер әле ул.

— Үскәч без дә бодай чәчәрбез әле, Оксана, әйе бит.

— Әйе шул. Син тракторда йөрерсен, ә мин, әни кебек, чәчкечкә басармын, яме,— ди Оксана. Ул шунда ук бүрәнә өстенә басып күрсәтә.

Оксана тагын минем яныма утыра. Ул кинәт күңелсезләнеп киткән шикелле тоела. Мин беләм инде. Шундый чакта сеңелемнең ачык зәңгәр күзләре карасу булып китәләр. Ул пышылдап кына сөйли башлый:

— Безнең тагын да бер әни бар иде бит, Җәмил. Ул бик еракта, еракта калды...

—Әкияттәме, борын-борын замандамы, Оксана?

— Түгел. Ул да бик яхшы иде.

Мин сеңелемнең сүзләрен анламыйм. Ничек инде ул ике әни булсын ди? Мин беләм инде— дөньяда бөтен кешеләрнең дә атасы да, анасы да берәр генә була. Дәү әнием шулай дип үзе әйтте.

Мин, Оксана еламаса ярар иде дип, куркып киттем. Юк, сеңелем еламый. Ул бер сүз дә эндәшми, тик кенә утырып тора. Җил аның коңгырт чәчләренә кушып үрелгән кызыл тасманы селкетә. Ул тасма, түбән очтагы клуб түбәсенә куелган флаг кебек, җилбердәп тә куя. Үзем тасмага карыйм, үзем эчемнән Оксананың әйткән сүзләрен кабатлыйм: „Еракта, еракта калды...“ Кем ул еракта калган әни? Әнием өйгә кайткач, мин аннан да сорадым инде. „Оксана, бәлки, сиңа төшен сөйләгәндер“,— ди әнием. Нигә андый төшләр күрә икән минем сеңелем? Оксанага нииндидер әйбәт сүзләр әйтәсем килә.

— Әйдә, бакчага керәбез, Оксана,— дим бик озак торгач,— әнә теге каен төбендәге хәзинәне сиңа бөтенләйгә бирәм. Күрсәң, исең китәр.

Сеңелем бакча ягына карый.

— Каен төбендә әле җир дә кибеп бетмәгән...

— Бетмәсә ни. Чак кына калган инде. Кояш аны барыбер киптереп бетерәчәк... Әйдә инде, Оксана.

УСАЛ АТА КАЗ

Кинәт урам капкасы астыннан Марат сеңелесе Фәһимәнең сары башы килеп чыкты. Безнен очта андый сары чәчле кыз берәү генә. Шунда ук, шуышып кына, Фәһимә үзе дә килеп керде. Бер Фәһимә генә түгел, без барыбыз да капка астыннан кереп-чыгып йөрибез. Элгече биек шул безнең капканың. Марат кына, капканы ача алмаса, койма башыннан үрмәләп керә. Янәсе, зур имеш, сигез белән бара.

Фәһимәне күргәч, Оксана көлеп үк җибәрде. Дусы килгәч, кем дә шатлана инде.

Фәһимә ике кулына ике кәгазь чәүкә тоткан. Ул, йөгереп килеп, бер чәүкәсен Оксанага, берсен миңа сузды. Үзе сакаулап-сакаулап сөйләргә тотынды. Зурлар да аптырый инде. Әллә нишләп сакаулыгы бетми шул Фәһимәнең. Үзе бит алты белән бара хәзер.

— Малат дүлт чәүкә ясады дүлтебезгә. Хәзел Фәлит белән монда киләләл. Чәүкә очылгач әй кызык булыл,— ди Фәһимә. Үзе Оксанага биргән чәүкәсен кире алып очырып та җибәрде.— Күлдеңме?— Кәгазь чәүкә кыйпылып-кыйпылып очып китте. Оксана куанычыннан кулын чәбәкләп куйды.

Икенче чәүкәне мин Оксанага бирдем. Ул, иң өстәге бүрәнәгә менеп, аны очырып җибәрде. Кәгазь кош әйләнеп-әйләнеп очып китте дә теге кечкенә бәбкә янына барып кунды. Бәбкә, куркуыннан ахры, баскан җиреннән егылып төште. Мин сизми дә калдым — сеңелем бәбкә янына йөгерде. „Ой, бәләкәчем, тәпиең авырттымы әллә?“ — дип каз бәпкәсен күтәреп алмакчы булды. Нәкъ шул вакытта ата каз, ачу белән очынып, сеңелемнең күлмәген килеп тешләде. Аннан соң, канатларын киң җәеп, Оксананы сугып та екты. Сеңелем ачы итеп кычкырып җибәрде. Фәһимә еларга ук тотынды.

Мин, чабып барып, ата казның канатына тотындым. Ул шунда ук Оксананы ычкындырды да минем беләгемне чукып алды. Казның канаты кулымнан ычкынып китте. Ата каз тагын да ачулана төште, ахры. Инде ике канаты белән берьюлы мине кыйный башлады. Мин ата казның тонык усал күзләрен генә күреп калдым. Үзем нәрсәгәдер абынып киттем. Шуннан соң берни күрмәдем дә, ишетмәдем дә, ике кулым белән битемне каплап, бөгәрләндем дә җиргә

йөзтүбән яттым. Еламадым да, кычкырмадым да. Минем елый торган гадәтем дә юк. Ә ата каз мине һаман өзгәли бирде...

Кемдер мине күтәреп алып аякка бастырды. Бер күземне ачканда, минем алда Мансур бабай тора иде. Аның янында Маратлар, Фәритләр, Фәһимәләр буталып йөри. Ә Оксана әле һаман күзләрен уа-уа елап тора. Мине жәлләп елый ул, беләм инде.

— Ике күзеңне дә ач әле, улым,— ди миңа Мансур бабай,— кош түгел бу каз, дошман бу. Харап итә язды бит баланы.

Шунда ук минем күңелем тулып китте. Өстемдәге яшел күлмәгемнең ертылып беткәнен күргәч, тагын да кыенрак булды.

— Ничә әйттем Көнбикәгә: ата каз түгел бу, ерткыч бу. Балаларның йөрәкләре ярылуы бар.— Бабайның тавышы миңа шундый ягымлы булып ишетелә. Аның муеныннан кысып-кысып кочаклыйсым килә минем. Ә Марат эре генә сөйләнгән була.

— Ярылды ди, мине котырган эт таласа да, йөрәгем ярылмады әле. Миңа эләксә, казыгызның муенын борып ташлаган булыр идем.

— Ташлал идең? Әтәчтән дә кулкасың әле.

— Ә син зурлар сүзенә кушылма. Бар, курчагыңны уйна.

— Фәһимә дөрес әйтә. Син — мактанчык,— ди Фәрит.

— Минме?

— Син!

Мин Маратның артына яшергән йодрыгын күреп калдым.

— Әй сез, көзге әтәчләр, көш!— ди Мансур бабай.— Тату гына уйнагыз. Тукта, Оксана кызым, елама инде. Хәзер әниегез кайтыр. Иртәгә

Май бәйрәме бит, балалар. Татулык кирәк.— Шулай диде дә капкадан чыгып та китте.

ҖИҢҮ АЛМАГАЧЛАРЫ

Иртәгә Май.

Без инде барысын да оныттык. Бишәүләшеп тотыныштык та сикерә башладык:

— Иртәгә Май! Иртәгә Май! Иртәгә Май!

— Тәзкилә апа мине илтәгә уламда йөлелгә алып чыга, белдеңме?

— Ә без үзебез барабыз, әнием җибәрә,— ди Оксана,— флаглар да тотарбыз — кызыл ситсыдан ясаганны.

— Әйдәгез, бишәүләшеп бергә барабыз, юк, алтаулашып. Минем энем Заман да иярсен,— моны Фәрит шулай ди. Ул гел бергә йөрергә ярата. Марат кебек түгел.

— Ә кем безнең башлык булыр соң? Юри генә булса да я звеновод, я бригадир кирәк.

— Юри генә түгел, чын кирәк. Звеновод та түгел,— вожатый. Шуны да белмисез, бала-чага!— Мондый эре сүзне Марат сөйли иде. Сигез белән бара бит ул!

Оксана белән Фәһимә: „Фәрит булсын!"— диләр. Марат үпкәли. Мин тик торам. Фәрит кинәт кычкырып җибәрә:

— Малайлар, әйдә шобага тотабыз. Кем өскә чыга, шул башлык була!— Моңа Марат та риза.

— Ә Заман? Ул да тотса, әллә өскә дә чыгар иде...

— Заман минем энем,— ди Фәрит,— Марат икенче кулы белән Заман өчен тотсын, мин риза. Сез ризамы?

Марат, тиз генә keләт ишеге янына барып,

каз оясы үргәннән калган тал чыбыгын алып килә. Без бишәүләшеп шобага тота башлыйбыз.

— Шобага тоттык, өскә килеп чыктык,— бер, ике, өч...

Шобага тоткан саен гел Марат кына өскә чыга. Әллә хәрәмләшә инде, әллә үзенең шобагадан бәхете бар? Бу юлы да чыбыкның очын гына учына кысып селтәде дә ыргытып бәрде.

— Тик Малат мине төлткәләмәсен, ялалмы,— ди Фәһимә.

— Вожатый төрткәләми ул. Бик белеп тор аны. Тик сакау көеңә күп сөйләнеп йөрмә.— Юк, Марат бу юлы сеңелесенә ачуланмый. Вожатый булган өчен генә шулай кычкырып сөйли.

Марат безне, җиңнәрдән тотып-тотып, тезеп куя. Иң алга Фәритне, аннан Оксананы, аннан мине, иң азактан Фәһимәне бастыра. Үзе бер читтә генә торып команда бирә башлый.

— Алга! Бер, ике, өч! Бер, ике, өч!

Без кузгалып китәбез. Тик Фәһимә генә, нигез буендагы бәрәннәргә карап, басып кала. Без капка төбенә якынлашканда гына, ул, йомгак кебек тәгәрәп, килеп җитә. Марат безгә туктарга куша.

— Туктагыз дим бит инде! Бер, ике!

Шул чак капка ачылып китә. Төбе-тамыры белән куптарылган кечкенә генә агачлар күтәреп, әнием килеп керә. Аның кояшта янган битендә бөрчек-бөрчек тир тамчылары ялтырап тора. Ачык капка төбендә туктап, әни аптырап кала:

— Бу нинди гаскәр тагын?

Без барыбыз да берьюлы җавап бирәбез:

— Иртәгә Май! Марат — безнең вожатый!

Әни озак итеп миңа карап тора. Аның йөзендәге елмаю акрынлап югала. Ул пошынып миннән сорый:

— Ә син соң, Җәмил, кайсы фронтта булдың?

Мин эндәшми генә башымны иям. Оксана белән Фәһимә икесе берьюлы ата каз турында сөйли башлыйлар. Марат өстәп куя.

— Мансур бабай белән без булмасак, Көнбикә апа, Җәмил беткән иде бүген,— дигән була.

Кулындагы агачларын бакча капкасы янына илтеп ташлый да әни Оксана белән мине җитәкләп ала.

— Юләрләр,— ди әни йомшак кына,— шулай саксыз йөрмиләр инде. Һәркемгә дә бала кадерле бит. Кешегә дә, казга да... Бүген бодайны чәчеп бетердек. Төштән соң мин эшкә бармыйм. Менә алмагачлар алып кайттым. Чәй эчкәч, бергәләшеп шуларны бакчага утыртырбыз.

Аннан Маратка борылып өстәп куя:

— Син дә отрядыңны алып кил, вожатый, ярыймы.

— Ярый, Көнбикә апа,—ди Марат кычкырып. Үзе Фәрит белән Фәһимәне төрткәләп урамга алып чыгып китә. Әнием кинәт кенә иелеп, ике кулы белән икебезне кочаклап, битләребездән үбеп ала. Үзе акрын гына сөйләнә: „Балаларым минем, күгәрченнәрем“,— ди.

* * *

Чәй эчкәч без өчебез дә бакчага чыктык. Әнием үзе тимер көрәк алды. Оксана белән миңа кечкенә тимер тырманы тоттырды. Без тырманы, икәү җигелгән булып, өстерәп килдек.

Бакчага кергәч тә әни, көрәген киртәгә сөяп, безнең кулдагы тырманы алды. Ул башта былтыр чөгендер утыртылган түтәлләрнең чүпләрен тырмалап бер урынга өеп куйды. Оксана белән без ул чүпләрне койма буена ташып та бетердек.

Аннан соң әнием алга килеп төшкән чәч толымын артка алып ташлады да көрәккә тотынды.

— Мәгез, инде сез башка түтәлләрне тырмалагыз,— диде әни, ә мин казый башлыйм.

Ул көрәген батырып-батырып җирне казый башлый. Агачны утырту өчен, башта чокыр ясарга кирәк шул. Кичә Мансур бабай да шулай итте. Ул да ике алмагач, дүрт чия агачы утыртты. Үзе Оксана белән безгә әйтә: „Бу агачларның җимешләрен мин күрә алмам инде, балалар, картайдым,— ди.— Ә сез үсеп җиткәндә аларның җимешләре өлгерер. Мин күрмәсәм, сез күрерсез. Мин шуңа ризамын... „Бабай билен уа-уа чак кына басып тора да тагын сөйли башлый: „Дөньяда кеше үзе өчен генә яшәргә тиеш түгел. Әнә, кояшны карагыз, ул бөтен җирне җылыта...“

Без, Оксана белән икәүләп, кулларыбызны каш өстенә куеп, күккә карыйбыз. Баш өстендә, зур күк түбәсендә, кечкенә кояш тора. Ул үзе эссе, үзе якты.

Безнең әни эшләгәндә сөйләргә яратмый. Әнә, әле дә кызу-кызу җирне казый. Иелгәндә аның чәч толымнарына тагылган чулпылары чылтырап китә.

Оксана белән без, тырмага җигелеп, башка түтәлләрне тырмалап йөрибез. Тик нигәдер әни тырмалагандагы кебек түгел — чүпләр җыелып өелми.

Урамда берәү сызгырып җибәрде. Бу Марат инде, ул гына шулай сызгыра белә. Шунда ук койма өстеннән Маратның башы калкып чыкты. Тик, әнине күреп алгач, бик тиз кире посты. Әни өйдә чакта ул койма башыннан йөрергә шикләнә. Шул арада Заман, Фәһимә, Фәрит капка астыннан бер-бер артлы шуышып кереп тә

җиттеләр. Бу юлы вожатый үзе дә тегеләр кергән җирдән генә керде.

Безнең янга иң алдан йөгереп Заман килеп житте. Аңа беркөн генә дүрт яшь тулды, ә үзенең бүреге миңа да зур. Башы бик зур аның.

Заман әни каршысына ук килеп басты.

— Көнбикә апа, безнең әнинең уймагы базга төшеп китте. Әй эзләдек, әй эзләдек,— табып булмады, ерак качкан,— ди ул, үзе бакчаның аргы ягына җәһәт кенә йөгереп китә.

Әни эшеннән туктамыйча гына көлеп куя.

— Көнбикә апа, миңа Сибәл әби матур күлмәк текте, Май бәйләменә.

Марат аңа турсаеп карый:

— Күлмәк тә, күлмәк ди, ә әтидән килгән хатны әйтми. Көнбикә апа, әле генә әтиемнән хат килде. „Җиңеп барабыз",— дигән.

— Безнең әтидән дә килде инде, иртәнчәк,— ди Оксана,— беләсеңме?

Әни инде көрәгенә таянып безгә карап тора. Аның йөзе шундый якты. Эчендәге шатлыгы шулай һәрвакыт аның төсенә чыга. „Көнбикәнең эчендә куанычы булса, ул үтәдән-үтә күренеп тора. Йөрәгендә тап юк минем баламның",— ди дәү әни.

— Бәйрәм килә, балалар, безнең урамга зур Җиңү бәйрәме килә,— ди әни. Аның тыныч тавышы миңа бик матур җыр төсле ишетелә.

Без барыбыз да берьюлы кычкырып җибәрәбез:

— Бәйрәм килә! Бәйрәм килә!

* * *

— Әйдәгез, балалар,— ди әнием,— хәзер инде алмагачларны утырта башлыйк. Үзегез зур үскәч,

бәләкәйләргә сөйләрсез: „Бу алмагачлар фашистны җиңгән елны утыртылды“,— дип әйтерсез.— „Җиңү алмагачлары болар“,— диярсез. Барыгыз, малайлар, агачларны берәмләп кенә монда ташыгыз.

„Малайлар“ дигәч, Заман да безгә ияргән була. Үзе без күтәргән агачның чыбыгына гына тотынып йөри.

Әни без ташыган алмагачларны чокырга бастырып куя да безнең өчебезгә — зур малайларга — аз гына күтәреп торырга куша. Үзе көрәк белән агачларның төпләрен күмә. Оксана белән Фәһимә киртә буенда үскән сары чәчәкләрне җыеп йөриләр. Ә Заман бөтен эшне дә эшли. Эшли дигәч тә, бутала инде шунда. Әле без тотып торган агачка килеп ябыша, әле учы белән чокырга туфрак салган була.

— Менә Заманның, ичмасам, эшләмәгән эше юк,— ди әни,— тик борынын сөртеп алырга гына вакыт тими.— Заман шунда ук җиңе белән борын астын ышкып ала. Без, малайлар, пырхылдап көлеп җибәрәбез. Көлмәслек тә түгел шул: Заманның түшендә почмагыннан булавка белән каптырып куелган кулъяулык бар. Үзе борынын җиңенә сөртә. Без көлгәч, ул борынын кулъяулыгы белән икенче кат сөртеп куйган була. Бала дисәң дә бала шул.

Менә без бөтен агачларны да утыртып бетердек. Аларны үсеп утырган чын агачлардан аерып та алырлык түгел. Бөтенебез дә иң азактан утыртылган агач янына җыелдык. Мин агачларны санап карыйм: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү. Барысы биш агач. Эчемнән генә уйлап торам: монысы әтиемә, монысы әниемә, монысы Оксанага, монысы миңа. Ә бишенчесе кемгә була соң?

— Ә бишенче алмагач кемнеке була соң, әни?— дим мин.

— Ничек кемнеке?

— Ничек булсын, шулай. Дүртесе дүртебезгә, монысы кемгә була?

Әни, елмаймыйча, тыныч кына җавап бирә. Әллә ачулана инде:

— Өйдәге нәрсәне бүлешмиләр аны, улым. Барысы да безнеке. Әнә, Үгез тавындагы зур бакча да безнеке.

— Сезнеке генә түгел әле ул, Көнбикә апа, аны минем әнием дә утыртты,— ди Марат.— Мин дә дүртне утырттым.

— Шуның өчен дә безнең барыбызныкы, дим дә мин, берәү дә бит бүлешеп йөрми.

Оксана әнинең итәгенә сыена. Әни аның башыннан сөеп ала.

— Әни,— ди Оксана,— чын түгел, ди, юри генә, ди, әни, яме?

— Нәрсә, кызым?— әни Оксананы бөтенләй иелеп тыңлый.

— Юри генә, ди, әни, бишенче алмагач кемгә булыр икән?

Әни Оксананы кочаклап күтәреп ала:

— Кызым да сорагач, әйтим инде: бишенче алмагач килгән кунакныкы булыр, яме?

Әһә, әни дөресен әйтте. Без өйдә өчәү генә торабыз. Безнең урындыгыбыз бишәү, чынаякларыбыз алты пар, тәлинкәләр тагын да күбрәк. Кем өчен соң аның артыгы? Хәзер белгәнсездер инде — кунаклар өчен. Без кунак килгәнне бик яратабыз. Мансур бабай беркөн әйтә: „Кунак йөзе күрмәгән кеше шатлык йөзе күрми ул“,— ди. Безнең радио сөйләгәнне тыңлагач шулай әйтте ул. Әллә радио берәрсен кунакка чакырдымы икән?

— Менә балаларга зур рәхмәт, хәзер уеныгызда булыгыз инде,— ди әни.

— Көнбикә апа, миңа да рәхмәтме?— дип сорый Заман.

— Заманга рәхмәтнең иң зурысы инде,— әнием шулай дип Заманны үбеп ала.— Замана баласы син, Заман.

— Әйе,— дип Заман баш ия.

Тегеләр бакчадан чыкканда, мин йөгереп кенә хәзинәм янына барып киләм. Каен төбендә чак кына су бар шул әле. Хәзинә сарае шул су астында ята.

Мин яңа утыртылган бер алмагач янында чак кына туктап торам. Бу алмагач — арада иң матуры. Эчемнән генә „шул иң матуры Оксанага булыр“,— дип уйлыйм. Аны чак кына сыйпап та куям.

Урам капкасы төбендә мин тегеләрне куып җитәм, капканы әнием үзе ачып бирә. Без барыбыз да урамга чыгып йөгерәбез. Мин Оксананы җитәкләп алам да артыма әйләнеп карыйм. Әни, көрәк сабына таянып, карап кала. Ә без Тимербулат бабайлар тыкрыгыннан Кыр ягына ук чыгып китәбез. Авылның ул ягын шулай „Кыр ягы“ дип йөртәләр. Анда тирән чокыр да, сай чокыр да бар. Җәй көне шунда бозаулар да, бәрәннәр дә, тайлар да үлән ашап йөриләр.

ЧУКЛЫ БАШМАКЛАР

Мин Казангол сыртына килеп җиткән көтүне күреп калдым... „Көтү кайтты, малайлар!“— дип кычкырып та җибәрдем. Иң алдан кәҗәләр, аннан соң сарыклар чабышып, урам очына килеп тә керделәр. Менә нинди озак уйнаганбыз Кыр

ягында. Без бөтенебез дә урамга табан йөгердек.

Безнең капка ачык иде. Көтү кайтыр алдыннан без шулай ачык куябыз капканы. Оксана белән икәүләп йөгерешеп болдырга мендек. Ә беләсезме, нәрсә күрдек без болдырда?.. Ишек янына гына сөяп куелган таяк күрдек. Җиз башлы кара агач таяк. Кем таягы дисезме?— Тимертаудагы дәү әни таягы ул. Менә кемнең таягы килгән безгә.

Без, таякны тотып та карамыйча, өйгә атылып кердек. Дәү әнием, кызыл камзулын киеп, өстәл янында утыра. Оксана белән икебез дә дәү әнинең муенына килеп асылынабыз — сеңелем алдан, мин арттан кочаклыйм. Аны күрәсебез килеп беткән иде шул инде. Әниләрнең март бәйрәменнән бирле килгәне юк иде безгә. „Һай, зирәкләрем минем“,— ди дәү әни. Көлгән чакта аның авызындагы кителгән теше күренеп кала. Мин дәү әниемне уйлаганда аның шул теше гел күз алдыма килә.

Дәү әни кулларын камзул кесәләренә тыгып ала. Ул башта безгә кесәсеннән ике йомырка чыгарып бирә. Икебезгә дә берәрне. Аннан соң кәгазьгә төрелгән тагын бернәрсә китереп чыгара. Нәрсә икән ул кәгазь эчендә? Дәү әни төргәкне тиз генә сүтеп ташлый. Төргәк эченнән шомырт күзле кечкенә генә камыр тургайлар килеп чыга. Болары безгә икешәр тиде. Ул тургайларны дәү әнием үзе пешерә белә.

Дәү әнинең итәгеннән төшеп, сеңелем белән икәүләп сандык өстенә барып утырабыз да тургайларның койрыгын тешләп алабыз. Мин аларны Оксанадан тизрәк ашап бетерәм. Соныннан гына шомыртларын чыртлатып чәйнәп куйган булам.

Дәү әни белән әни бер-берсенә карашып алалар да, әнием чаршау эченә кереп китә. Без теге бүлмәне, чаршау белән бүленмәсә дә, чаршау эче дип йөртәбез. Чаршавы юк,— ә чаршау эче бар — кызык инде шулай.

Әни, ике кулын артка яшереп, шунда ук кире чыга.

— Монысы кемгә?— дип сорый ул.

— Нәрсәнең монысы соң, әни?

— Соңыннан күрерсез, әйтегез инде тизрәк,— дип ашыктыра дәү әни. Мин әллә нишләп китәм. Тыным кысылгандай булып кала.

Әни, башы белән сул якка күрсәтеп, янадан сорый:

— Алай булгач син әйт, Оксана, кемгә монысы?

— Җәмилгә.

— Ә тегесе Оксанага,— дип әйтеп өлгерәм мин. Әни берьюлы икебезгә дә берәр пар башмак суза, өр-яңа күн башмаклар.

— Дәү әниегез сезгә Май бүләге итеп алып килгән аларны, рәхмәт әйтегез,— ди әни. Без икебез дә дәү әнигә сарылабыз: „Рәхмәт, дәү әни, сиңа!“ дибез.

Әнием бер башмакны миннән кире ала да аның табанына бармагы белән төртеп күрсәтә:

— Болар бит,— ди ул,— Москвада эшләнгән. Менә язуы әйтеп тора: Москва, „Париж Коммунасы“ фабрикасы.

Ул башмакны әнием кире миңа бирә. Эх, күрсәгез иде сез ул башмакларны! Дүртесе дә сары күннән тегелгән, дүртесенең дә өстендә кызыл күннән ясалган чуклары бар. Менә башмаклар, ичмасам! Мин аларның чукларын сыйпап-сыйпап карыйм.

— Ягез, киеп карагыз әле, балалар, таманмы икән?— ди дәү әни.

Без тиз генә иске башмакларыбызны чишеп ташлыйбыз. Аларны чишкәч, әни безне туктатып тора:

— Булгач-булгач барысы да яңадан булсын инде. Болдырдагы тазда су бар, барыгыз, шунда аякларыгызны юып керегез дә, яңа оеклар кидерермен.

Болдырга чыкканда да без башмакларны калдырмыйбыз, алып чыгабыз. Аякларыбызны таздагы суга тыгып, сөйләшеп утырабыз.

— Зур үскәч без дә дәү әнигә матур - матур күлмәкләр алып бирербез, матур башмаклар тектерербез, яме, Җәмил,—ди сеңелем. Үзе, ике кулына ике башмагын киеп, туп-туры итеп басып караган була.

— Мин үскәч шофер булам да дәү әнине, әнине, әтине, сине, машинага утыртып, шәһәргә курчак театрына алып барам.

— Ә мин үскәч дәү әнигә үзем яңа камзул тегәм. Мин бит тегүче булам. Машинаны әйләндерәм дә тек-тек-тек тегәм дә куям.

— Син дәү әнигә тун да тек, Оксана, аның бит туны тузган инде...

Әни өйдән тәрәзә кага, үзе чакырып кулын болгый. Без болдыр идәнендә үзебезнең эзләребезне ясап чак кына йөрибез дә, әни биреп чыгарган чүпрәккә аякларны сөртеп өйгә керәбез.

— Я, сез, әллә суга баттыгызмы?

Кызык сүз әйтә әни — таздагы суга батып буламы инде?

— Киеп кара да биеп кара! — Мондый башмаклар кигәч, кеше ничек итеп биемичә түзеп торыр икән?— ди дәү әни. Башмакларны кигәч, без икебез дә идән буйлап йөреп карыйбыз. Бер Оксанага, бер үземә күз салам. Сеңелем баскан саен теге кызыл күн чуклар җилфердәп киткән төсле булалар.

Минем яна башмакларны киеп, урамга чыгып йөгерәсем, бөтен авылны әйләнеп кайтасым килә. Юк, алай гына түгел, әнә теге машиналар үтеп йөри торган олы юл белән еракка-еракка чабып китәр төсле булам. Үзем хәзер үк сеңелемне җитәкләп алырга телим. Нигә аяклар йөгереп китәргә генә тора икән бу кадәр? Әллә чынлап та, әкияттәге итекләр кебек үзләре йөри торган башмаклармы икән болар?

— Синең урамга чыгып йөгерәсең киләме, Оксана?— дип сорыйм мин.

— Килә. Әйдә чыгабыз.

Әни безнең янга килә дә, икебезне кочаклап алып, сандык өстенә утырта.

— Әнә кояш та тау артына төшеп китте. Тавыклар да кунаклады, бәрәннәр дә хәзер йокларга ята. Сез иртәгә кояш белән бергә торып чыгарсыз,— ди әни.— Кояш сезнең башмакларыгызны күргәч, үзе дә сокланыр әле: „Нинди матур әнә ул балаларның башмаклары!“ дияр.

Мин әниемнең шулай сөйләгәнен яратам. Кояшның нәрсә әйтерен дә белә шул ул әни кеше булгач.

— Әни,— ди Оксана,— башмакларны айга да күрсәтербез, ярыймы, әни?

— Сез йокларга яткач, ай үзе килеп тәрәзәдән карый ул.

— Ә йолдызларга?

— Йолдызлар ерактан күрмиләр, шуның өчен

аларга ай гына сөйләп бирер. „Менә мин бүген жирдәге ике баланың башмакларын күрдем, бик матурлар“,— дип әйтер ул. Ә йолдызлар жемелдәшеп көләргә тотынырлар. Шатлыклы сүз ишеткәч, алар да куанып, яктырып китәләр бит.

Әни сөйләгәндә, мин сеңелем белән икәүләп йолдызлар арасында атлап йөргәндәй булам. Менә нинди башмаклар китерде бит безгә дәү әни!

Караңгы төшкәч тә, без ятмый торабыз. Башмакларны да салып куясы килми. Кайчан гына иртә булыр икән? Без иң элек Маратларга, аннан Фәритләргә барыр идек. Су буена төшеп, комда да йөреп карар идек әле.

Дәү әни Оксана белән икебезгә урыннар җәеп бирә. Безнең кроватьларыбыз турында гына әтинең зур рәсеме эленгән. Ул яланбаш, күкрәгендә өч медаль тезелеп тора. Мыегы як-якка кыелып киткән. Бу рәсем элек кечкенә генә иде әле, былтыр аны Хисамиларга килгән бер такыр башлы, алтын тешле абый әллә ничек кенә зурайтып китте. Ул абый безне дә рәсемгә төшерде.

Мин һәркөнне кич әтиемә озак итеп карап ятам. „Ул кайда икән хәзер, ул нәрсә эшли икән?“ дип уйлыйм. Оксана да, билгеле, шулай уйлый. Әле рәсем ачык күренми. Ләкин мин барыбер аны күреп торган кебек. Күзне йомып та таный алам мин әтине.

Нигәдер һаман йоклап китеп булмый. Менә урам тәрәзәсеннән ай карады. Аның яктысы сандык өстенә төште. Ә сандык өстендә безнең башмаклар тора. Ул, мөгаен, мине дә Оксана кебек йоклыйдыр бу, дип уйлыйдыр әле. Мин күзләремне чак кына ачып карап ятам. Ай мине күрми. Нәрсә сөйли икән ул ай хәзер үзенең йолдызларына?..

Мин юрганны башымнан ук ябынып ятам. Кинәт Мансур бабайның сүзләре миңа яңадан ишетелгән кебек булып китә: „Иртәгә Май бәйрәме бит, балалар...“ Ничек йокы килсен, ди инде шундый чакта.

АКТЫ ДА КИТТЕ БЕР БАШМАК

Мин әнинең аяк тавышларын ишетәм. Ул әкрен генә басып өйдән чыгып китте. Ә мин барыбер ишетәм дә күзләремне ачам. Өйдә якты. Сеңелем әле уянмаган. Ул үзе йоклый, үзе көлә. Аның коңгырт чәчләре маңгаена төшкән. Мин торып утырам. Дәү әнием дә өйдә күренми, ә башмаклар күренә. Алар дүртәүләшеп сандык өстендә торалар. Мин сеңелемне уятам:

— Оксана,— дим,— әнә кояш та чыккан, тор инде.

Ул һаман уянмый, йодрыгы белән борын очын уып ала. Мин, сеңелемнең колагына ук иелеп, пышылдап кына әйтәм:

— Оксана, әнә башмаклар көтеп тора, уян инде, уян.

Сеңелем үзенең зур зәңгәр күзләрен ачып җибәрә дә сикереп тора. Без икебез дә ишек янына җәһәт кенә барып битләребезне юабыз. Безнең юына торган җиребез шунда.

Дәү әни сөт чиләген күтәреп килеп керә:

— Менә, җылы сөт эчеп алыгыз, балалар,— ди дәү әни. Ул икебезгә дә күбекләнеп торган сөт салып бирә.

Сөтне эчкәч тә без башмакларны кияргә тотынабыз. Дәү әни, Оксананың чәчен тиз генә тарап, теге кызыл тасманы тагып куя. Оксананың хәзер башмагында да, чәчендә дә кызыл чугы булды.

— Нинди уңган балалар болар, кояш белән бергә торып утырганнар,— ди әни кергәч.— Барыгыз хәзер, чәйгә кадәр урамда йөгереп уйнагыз. Бәйрәмгә барганда яңа күлмәкләр дә кидерермен.

Урамда бөтен кеше безнең башмакларга карый. Үзебез дә карыйбыз, кояш та карый. Ул карамаса, башмакларның өсләре ялтырап тормас иде бит.

Без иң элек Мансур бабайларга кердек. Фәрхениса әби, шүрлектәге чүпрәкне чишеп, безнең икебезгә дә берәр уч чикләвек бирде. „Җылы тәнегездә тузсын инде, башмакларыгыз бигрәк матурлар икән“,— ди ул. Үзенең күзләре күрми, ә үзе безнең башмакларның матурлыгын белә. Әллә әбигә Мансур бабай сөйләдеме икән? Ай йолдызларга сөйләгән кебек.

— Дәү әни китерде, әби, кызыл чуклары да бар,— ди Оксана. „Кая әле, кызым“,— дип, әби Оксананың аягын капшап карый. Үзе һаман мактый. „Бигрәк йомшак та икән үзләре. Бармакларым рәхәтләнеп китте, рәхмәт төшсен инде дәү әниегезгә“,— ди ул.

— Күзе күрмәсә дә, күңеле күрә шул әбиегезнең,— дип куя Мансур бабай.

Мансур бабайлардан чыгып, Маратларга киттек. Без җитәкләшеп, атлап кына барабыз, йөгермибез. Үзебезнең түбәнгә генә карыйсы килеп тора.

Марат келәтләре янындагы бүкән өстендә агач юнып утыра. Ул кылыч ясый да кылыч ясый. Үзе борынын җыерып безгә карап тора:

— Әллә-лә-лә, болар яңа башмаклар кигәннәр икән!

— Кигәннәр шул.

— Кисә, ис китәме әллә! Мин итек яратам,—

дигән булып, ул пычагы белән итек кунычына сугып ала, үзе тагын безнең башмакларга карый.

Оксана, аягын күтәреп, башмак табанын Маратка күрсәтә: „Әнә язуы да бар“,— ди. Марат бер дә исе китмәгәндәй утыра.

Мин, чалбар кесәсеннән алып, Маратка үземнең уч белән бер уч чикләвек бирәм. „Рәхмәт, ди миңа Марат.—Башмак котлаганнар инде, беләм. Чуклары матур гына... Сиңа да кылыч ясармын“.

Әллә ниндирәк шул Марат. Үзе вожатый, үзе эре, үзе барыбер дус.

Маратларның өй ишеге ачылды да, аннан елт итеп Фәһимә килеп чыкты. Ул безгә таба йөгерә, үзенең җирән чәчләре, тай ялы кебек, җилферҗилфер итеп китә. Өстендәге чәчәкле-чәчәкле яңа күлмәге күз явын алып тора. Фәһимә, килеп җиткәч, Оксанадан сорый:

— Матулмы минем күлмәгем?

Оксана аның чәчәкле күлмәген тотып-тотып ала. „Әй матур!“—ди, ә үзе түбән карый. Фәһимә әйләнеп-әйләнеп күлмәген мактатканда Оксананың башмакларын күреп ала.

— Әй, нинди башмаклал кигән! Я, йөлеп кала әле. Киләсе ел миңа да шундыйлалны алыллал әле. Чуклалы да чуклалы. Әйдәгез, су буена балабыз.

Марат эндәшми генә пычагы белән кылычын бүрәнә ярыгына илтеп кыстыра. Аннан соң күлмәгендәге йомычкаларны кагып ташлый.

— Әйдәгез!—дип безне урамга алып чыга.

Без су буена төшкәндә, арттан Фәрит белән Заман да килеп җитә.

— Без бәрәңге пәрәмәче пешердек, Оксана, тәмлене, икмәк тә салдык,—ди Заман, үзе иелеп сеңелемнең башмак чугын тотып карарга тели. Аны Фәһимә чак кына төртеп җибәрә:

— Өзәсең бит инде, Заман! — Заман ачуланмый. Ул, Сәгыйдә Ильясы кебек, җебегән малай түгел.

Ә безнең суны күргәнегез бармы соң? Юктыр шул. Әнә, ул Фәритләр йорты янына ук агып килә дә тугай ягына таба борылып китә. Безгә таба түгел, безнең янда Кыр ягы гына. Ул елганы Көмешле елгасы дип йөриләр. Җәй көне без анда су кереп йөрибез. Әле суы салкын аның. Таш ыргытсаң, теге читенә җиткереп тә булмый. Менә нинди киң ул! Безнең Көмешле берүзе генә ага-ага да бик ерак бер җирдә Агыйделгә барып кушыла. Аннан икәү булалар. Ә Мансур бабай әйтә: „Көмешлененең суы диңгезгә барып җитә аның“, — ди. Җитәдер дә шул, туктаусыз агып торгач. Үскәч сеңелем белән без дә диңгезгә, балыкчы бабай алтын балык тоткан җиргә барырбыз әле.

Менә шушы инде безнең Көмешле дигән елга. Без аны „Көмеш“ кенә дип йөртәбез.

Башта без яр буендагы юеш комлыкта эзләр ясап йөрдек. Иң матуры — яңа башмакларның эзе инде — Оксана белән минем эз.

Шуннан соң, „Ничә калач ашармын?“ — дип, кыйпылчык ташларны су өстеннән сикертеп-сикертеп ыргытып уйнадык. Су өстендә таш ничә кат сикереп китсә, шулкадәр калач ашаган буласың. Иң күп калач ашаганы Марат белән Фәрит булды. Оксана белән Фәһимә берне дә ашамаганнар иде дә, мин Оксана өчен, Марат Фәһимә өчен икешәрне кыйпылдырып бирдек. Заман комда тегермән тарттырып кына утырды.

Без, өч зур малай, тал чыбыкларыннан, төрле йомычкалардан сал ясарга тотындык. Сал бик кызык агып китә ул безнең суда. Фәрит, тал чыбыгын суеп, салны ныгытып бәйләп тә җибәр-

де. Сал әзер генә булгач, безнең янга түбән оч малайлары килеп житте. Алар да безнең кебекләр — зур да түгел, кечкенә дә түгелләр. Тик Хәйбулла Рушаны гына усал. Без Оксана белән почтага әтигә язган хатны илтергә барганда, ул гел таш ыргытып кала. Үзенең бер тидерә алганы юк. Я кулы чалыш ыргытадыр әле.

— Саумысез, югары очлар, — дигән була аларның Әхәте, — үзе бер Марат белән генә күрешә.

— Саумысез, түбән очлар, — дип җавап кайтара безнең Марат. Зур малайлар да очрашканда шулай итәләр.

Салның өстенә салырга мин коры үләннәр, яфраклар җыеп йөрим, Оксана белән Фәһимә яр читендә генә башмакларына тулган комны кагып утыралар. Сеңелем бер башмагын кулына тоткан, икенчесен салып, янына куйган.

— Сал әзер! — диде Марат. Аны иптәп кенә су читенә китереп куйды, Фәрит ботинкаларын чишеп, чалбар балакларын сызганды да салны эчкә этеп җибәрде. Нәкъ менә шул вакытта, югарыдан очып, сал өстенә бер сары башмак килеп төште. Мин Рушанның селтәнгән кулын гына күреп калдым. Башта аякларыма карадым. Минем ике башмагым да аягымда. Шунда ук ялт итеп сеңелемнең аягына карадым. Ул һаман да бер башмагын кулына тотып утыра. Үзләре Фәһимә белән кычкырып-кычкырып сөйләшәләр. Ә икенче башмак аның янында күренми.

— Башмак! — дип кычкырып җибәрдем мин, азрак торгач.

Мин кычкырганчы ук, Марат итекләре белән суга кереп китте. Су биленә тикле җиткәч, ул кире борылды. Ә сал һаман эчкә таба китте. Яр башында сеңелем елап җибәрде. Малайлар ара-

сында тарткалаш башланды. Фәрит Рушанны төртеп екты. Түбән оч малае Әхәт үзе Рушанның аркасына сукты. Рушан урам ягына таба йөгерде. Ә без салга карап калдык. Ул суның уртасына ук йөзеп чыкты. Сал өстендә кызыл чуклы башмак, туганымның башмагы бара.

— Их, көймә булса!—ди Әхәт.

— Җәй булса, мин йөзеп барып тотар идем...

— Ә мин чумып кына...

Мин сеңелем янына киләм. Ул тыпырчынатыпырчына елый. Аңа кушылып Фәһимә белән Заман да үкерәләр.

— Елама, Оксана, елама, хәзер чишәм дә бер башмагымны сиңа бирәм,—дим мин,—үзем һаман салга карыйм. Сал ерагайганнан-ерагая бара.

Хәзер башмакның чугы да күренми. Китте дәү әнием Май буләге итеп китергән бер башмак!..

Мин яр буйлап сузылган такыр сукмакны күреп калдым. Еез ул сукмак буйлап йөгереп әллә кая кадәр житкәнебез бар.

Берәүгә дә эндәшеп-нитеп тормый, тоттым да башмак артыннан йөгердем. Яр буеннан гына сукмак үзе алып бара. Мин, әзрәк киткәч, сукмак аркылы яткан чыбык-чабыкка абынып егылдым да борыным белән сөрлегеп киттем. Борын астыннан жылы нәрсә тама да башлады. Кул сыртым белән сөртеп карасам — кан. Сикереп торгач та, су өстенә карадым. Сал инде күздән югалып бара. Мин кычкырып елап жибәрдем һәм тагын да шәбрәк йөгерә башладым.

Инде сал белән минем ара якыная башлады. Елганың борылган бер жирендә башмакны куып та життем. Әнә бара ул. Үрелеп кенә алыр идем дә бит, буй житми. Их, әкият малае булса идем мин! Берәр аккош килер иде дә борынына гына эләктереп алып бирер иде шул башмакны. Мин дә аның берәр йомышын тыңлар идем.

Бик озак баргач, сал елга өстенә ауган бер зур талның ботагына килеп эләкте. Бераз тартылып торгач, ул су өстендә әйләнә башлады. Читкә дә чыкмый, уртага да китми, әйләнеп тик йөри бер тирәдә. Ыргаклы берәр озын чыбык булса, тартып кына алыр идем дә бит үзен.

Кояш су өстен ялт иттереп яктыртып тора. Карап та булмый — күз чагыла. Күрмиме икәнни инде, иртән үзе шатланып караган башмакларның берсе ни бәлагә төште бит?

Мин суның читенә үк килеп карап торам. Агып барган зур бер агачның башы салны төртеп жибәрде. Сал әйләнмәдән чыгып тагын агып китте.

Сал ага — мин йөгерәм, сал ага — мин йөгерәм. Диңгез еракмы икән әле? Ерак та калмагандыр инде. Диңгезгә житеп булса да, тотармын мин ул башмакны. Бер зур агач төбенә житкәч, минем алдыма ялбыр колаклы ала эт килеп чыкты. Ул, ике аягын сузып, сукмакка утырды. Авызыннан озын кызыл теле салынып тора. Мин курыкмадым аннан, тик елавымнан гына туктадым. Башта этне бер читтән урап үтәргә уйлаган идем, ялбыр колак минем алга сикереп чыкты да ырылдап җибәрде. Мин зур тирәк торган икенче якка йөгердем. Эт тагын минем алдыма килеп басты. Өрми дә, җибәрми дә Шул арада Көмешле салны тагын еракларак алып китте... Их, шушы вакытта ат менгән әтием бер кулына мылтык, бер кулына кылыч тотып килеп чыкса иде! Бу дошман эт үзе курkып качар иде. Җибәрми бит мине бу ала эт. Мин бер агып киткән башмакка, бер ямьсез ала эткә карап торам. Менә сал күздән дә югалды...

Кинәт урман ягыннан кеше тавышы яңгырап килде:

— Барбос!.. Бар-бос!..

Шуны гына ишеткән иде теге ялбыр колак, торды да чапты.

Мин алга йөгердем. Тагын да өч рәт егылганымны да, тиземне авырттырганымны да, битемне агачтан сыдыртканымны да сөйләп тормыйм. Йөгергән чакта андый гына хәлләр була инде ул.

Бу юлы мин тагы да шәбрәк йөгердем. Ә сал миннән әкренрәк йөзә. Менә мин аны тагын куып җиттем. Туганымның башмагына бер кечкенә генә кош килеп кунган. Аңа рәхәт. Их, ул әкият кошы булса, бер генә сүз әйтер идем үзенә...

Кошчыкка карап кына барганда, миңа ап-ак сакаллы бер бабай очрады. Ул иңбашына бер ишкәк салган, аркасына тубал аскан.

— Кая йөгерәсең болай, улым, үзең канга буялып беткәнсең? — ди бабай.

— Әнә башмак, өстенә кош та кунган, — дим мин, — без түгел, аны сал өстенә Рушан ташлады. Сеңелемнеке, ул елый. Әнә, әнә, күрәсеңме, бабай?

Бабай, кулын күз өстенә куеп, суга карап тора.

— Ачык кына күрмим шул, улым.

— Күр инде, бабай, күр әле, әнә генә бит!

Бабай, аркасындагы тубалын салып кәкре агачка элеп куйды да, тиз-тиз атлап, сукмак буйлап кире китеп барды. Мин аның артыннан йөгерә-йөгерә генә иярә алдым. Бер ерынтыны чыккач, бабай яр астына төшеп китте. Мин дә аннан калышмадым. Анда зур талга бәйләгән көймә тора. Бабай көймәнең бавын чиште дә, ишкәген алып, көймә эченә басты.

— Я, улым, утыр, киттек, — диде ул. Мин көймәгә утырдым.

Сал тагын күздән югалды. Теге кош кына алып китмәсә ярар иде башмакны. Ул да Рушан кебек усал булса, суга да төртеп төшерер әле. Тизрәк куып житсә идек тә бит! Бабай көймәгә баскан көе кызу-кызу ишеп бара. Аягы таеп китеп, бабай сөрлегеп куймаса ярар иде дип куркып беттем. Ул-бу булмады. Менә без салны куып життек. Теге кош очып

киткән иде. Бабай нигәдер башта салны читләбрәк үтеп китте. Аннары алгарак чыгып көймәне аркылы борды. Менә күрдегезме инде? Сал үзенәкъ бабайның каршысында гына көймәгә килеп сугылды. Бабай үрелде дә сеңелемнең кызыл чуклы сыңар башмагын алды. Әһә, каптыңмы кармакка! Менә нинди әйбәт икән бу бабай. Бабай башмакны миңа бирмәде, көймә төбенә куйды. „Я төшереп җибәрер, моңа бирсәң“,— дип уйлагандыр әле ул. Төшермәс идем, кысып тотар идем.

Без инде кайтыр якка таба яр буйлап кына йөзеп барабыз. Бабай ишкәк ишә, мин аннан әкрен генә сорыйм:

— Син әллә әкият бабаемы?

— Юк, мин чын бабай, балыкчы Яхшыгол карт мин,— ди ул.

— Син үзең чын, үзең Яхшыгол, үзең бик яхшы,— дим мин. Аны кочаклап аласым килә минем.

— Чын кешеләр барысы да әйбәт булырга тиешләр, улым,— ди бабай.— Һәм ул шулай да: заман үткән саен, чын кешеләр дә күбәя бара безнең җирдә.

Көймәнең борыны ярга килеп төртелде. Мин сөрлегеп китә яздым. Без бая утырып киткән җиргә килеп җиткәнбез икән.

— Чык инде, улым,— диде бабай.

Башта көймәдән мин төштем, аннан соң башмакны алып бабай чыкты. Ул көймәне бәйләгәч, яр башына мендек. Шунда гына бабай сеңелемнең кызыл чуклы сары башмагын миңа бирде:

— Мә, улым,— диде бабай,— башмагы бик килешле икән. Саклап кына кисен инде туганың.

— Рәхмәт, бабакай,— дидем мин, аның ботыннан кочаклап алдым. Муеныннан кочакларга буй җитми бит.

Килгән сукмактан бабай белән икәүләп кайтып та киттек. Ул мине җитәкләп алды. Бер сай гына елгага житкәч, бабай минем битемне, кулларымны юдырды. Без шунда икебез дә уч белән генә су да эчтек. Нинди рәхәт булып китте. Әнә бит, кошлары да матур итеп сайрап торалар. Кояш сон, кояш. Ничек югарыга ук менеп киткән ул! Су өстендә бибек-бибек дип акчарлаклар очып йөри. Агачлар да, әле генә үсеп чыккан сары чәчәкләр дә, кошлар да, бабай да, мин дә — барыбыз да шатланабыз. Шатланмаслыкмы соң? Үзе яз, үзе җылы, үзе рәхәт, үземнең кулымда табылган башмак бар.

Кәкре агачка җиткәч, бабай тубалын алып аркасына асты.

Без инде тавыш-тынсыз гына барабыз.

Бабай тукгап бишмәтенең түш кесәсеннән озын чылбырлы сәгатен алып карый:

— Бәй, улым, без бит бәйрәмгә соңга калабыз. Сәгать тугызны сугарга тора, әйдә, кызурак киттек, — ди.

Бәйрәм! Мин әллә нишләп киттем: соңга калмасак кына ярар иде.

Мин бабайның чабуыннан тарткалыйм:

— Әйдә йөгерик, әйдә! — дим.

— Минем итекләрем бик авыр шул; бар, син алдан йөгер, бар, — дип, ул мине җитәкләп үз алдына чыгара. Башмакны җайлап кына тотып алдым да сукмак буйлап чабам гына. Ә бәйрәм беткән булса? Ну, шушы Рушанны, ниләр генә күрмәдем шунын аркасында. Сеңелемне елатып бетерде... Артка әйләнеп карап алам. Баштарак бабай бик калышмаган иде дә, соныннан калышты.

Ә кемнәр йөгереп килә соң бирегә табан? Берсе зур, икенчесе кечкенә. Әллә аларның да

башмаклары агып киттеме икән? Мине күргәч, алар тагын да кызурак йөгерә башладылар. Таныдым, таныдым! Зурысы әни. Тегеләре кемнәр дисеңме? Берсе Марат, ә иң арттан йөгергәне Оксана. Менә кемнәр килә.

Әни хәле бетеп килеп җитә дә мине күтәреп ала.

— Котны очырдың бит, балакай...— ул мине кысып-кысып кочаклый, битләремнән, башларымнан үбә. Ә минем бөтен уем бәйрәм турында.

— Бәйрәм бетмәдеме әле?— дип сорыйм.

Матур түбәтәе белән битендәге тирен сөртеп торган Марат җавап бирә:

— Юк әле, башланмады да.

Иң соңыннан Оксана килеп җитә. Шунда ук әни мине җиргә төшерә. Сеңелем йөгереп килеп мине кочаклап ала: „Җәмил, Җәмил,— ди ул,— әбез куркып беттек!“— Мин аңа башмакны бирәм:

— Балыкчы Яхшыгол бабай белән икәү тотып алдык, көймә белән барып.

Сеңелем башмагын күкрәгенә кыса. Әни бигрәк куана инде. Икебез дә табылдык бит: мин дә, башмак та.

Безнең янга Яхшыгол бабай килеп туктый:

— Бәйрәм котлы булсын, Көнбикә! Синең улыңмыни бу?

— Минеке. Рәхмәт инде Яхшыгол абзый, юкса, бәйрәмнең яме китә язды бит.

— Үткер малайга охшый. Ярый, ярый, бик әйбәт. Безнең заман үткер ирләр сорый...

— Башмагы артыннан үзе төшеп китмәсә ярар иде дип курыктык. Бигрәк туган җанлы бала... Барыгыз, балалар, алдан йөгерегез,— ди әни.

Без, әни белән Яхшыгол бабайны артта ук калдырып, урамга килеп керәбез. Урамның түбән очындагы клуб башында зур кызыл флаг тал-

пынып-талпынып җилфердәп тора. „Бәйрәмгә килегез, бәйрәмгә килегез, балалар!“ — дип, безне чакырадыр әле ул флаг...

МИН ЧЫН ФЛАГ ТОТЫП БАРАМ

Дәү әни әйткәндәй, чуктай итеп киенеп, яңадан урамга чыгабыз. Без бик күбәүбез. Санап та бетерерлек түгел. Иң зурысы — Бадамша бабай кызы Тәзкирә апа. Ул әллә ничәнчедә генә укый инде — әллә алтынчыда, әллә җиденчедә.

Клуб түбәсендәге флаг һаман да безне чакырып җилфердәп тора. Без шул флаг ягына табан китеп барабыз. Бәйрәм саен кешеләр башта шунда җыелалар да, байраклар, Ленин белән Сталин бабайның портретларын күтәреп, урамнар буйлап йөриләр. Мин әнием белән бәйрәмдә ике тапкыр йөргәнем бар инде. Берсе — үткән ел Майда, берсе — Октябрьда. Үткән ел Майда мин арыдым да, әнием әзрәк кенә күтәреп барды. Кечкенә идем шул әле мин ул чакта.

— Ә нигә соң бәйрәмдә кешелер урамга чыгып йөриләр, әни? — дип сорадым мин шул чакта. Әнием миңа сөйләп бирде:

— Дөньяда безнең дусларыбыз да, дошманнарыбыз да күп. Без җыелышып урамнарга чыккач, ерак илләрдәге дусларыбыз безне күрә дә: „Әнә, безнекеләр ничаклы, үзләре бердәм, үзләре көчле! — дип шатланалар. Барыбыз да бергә җыелгач, күңелле була бит.

— Ә дошманнар ни эшли? — дип сорыйм мин.

— Дошманнар куркалар, аларның котлары оча, белдеңме инде?

Белдем инде. Дошманның да кемлеген беләм мин: фашистлар я буржуйлар. Шуларны җиңеп йөри бит инде әти.

Менә без җыелышып урамга чыктык. Дуслар шатлансыннар, ә дошманнның коты очсын. Алдан вожатый Марат бара, аның артыннан Фәрит белән мин, безнең арттан кечкенәләр ияргән. Тәзкирә апа читтән генә атлап килә. Түбән очка якынайган саен, без күбәя барабыз. Очраган бөтен бала безгә килеп кушыла. Нинди күңелле икән бәйрәмгә бару!

Клуб янында халык бик күп. Зурлар төркем-төркем булып сөйләшеп торалар. Егетләр белән кызлар түгәрәкләнеп басканнар. Түгәрәк эчендә нәрсә барын ерактан күреп булмый, әллә бииләр инде? Бер кыз кычкырып-кычкырып җырлый. Минем кебекләр йөгереп уйнап йөри.

— Килеп җиттегезме, картлар? Бик соңлап йөрисез,— ди безгә бер абый, үзе көлә. Аның исеме Рәшит. Кызык сүз әйтә Рәшит абый, бәләкәй кешеләргә „картлар" ди.

— Болар килгәч, кузгалырга да ярыйдыр инде, Рәшит,— ди укытучы Сания апа. Мин аны беләм. Ул матур апа безнең очта тора.

Кешеләр тезелә башлыйлар. Безне, бәләкәй балаларны, иң алга китереп бастыралар. Мине Оксана белән янәшә куялар. Минем икенче якта арткы урамның бер малае. Мин аны таныйм да, исемен генә белмим. Фәрит белән Фәһимә безнен артта, Марат әллә кайда буталып калды, күренми. Мин артка әйләнеп әниемне эзлим. Тик табып кына булмый.

Оксана минем беләгемнән тарта.

— Җәмил, әнә әни,— дип сеңелем бармагы белән төртеп күрсәтә.

Әни безнең алга килеп чыкты. Үзе күңелле, үзе матур безнең әниебез. Әле аның кайсы җиредер безнең әнигә охшамаган да төсле.

— Җитәкләшеп кенә йөрегез, яме,— диде дә

әни, зурлар тезелгән якка китеп тә барды. Без аңа кул болгап калдык.

Бер пионер апа алда торган бөтен балаларга да бәп-бәләкәй генә кызыл флаглар таратып чыкты. Тик миңа гына җитми калды. Мине күрми үтте ахры. Ул кадәр бәләкәй дә түгелмен инде. Миңа кыен булып китте. Теге, арткы урам малае белән Оксана берьюлы кычкырып җибәрделәр.

— Апа, апа, бу малайга флаг тимәде.

Оксананың „бу малайга“ дип әйтүе миңа ошамый.—„Җәмил“ дисә дә ярар иде инде.

Башымны түбән иеп кенә карап торам. Теге апа шул арада каядыр китеп тә барды.

— Җәмил, Җәмил, алмашлап тотарбыз, үпкәләмә, Җәмил!— бу сүзләрне минем сеңелем әйтә. Аның тавышы миңа тагын да ягымлырак булып ишетелә. Мин, елап җибәрүдән куркып, башымны күтәрмим. Шул чак башмаклар агып китүе дә, кызыл телле ала эт тә, борын канаганы да исемә килеп төшә. Әллә минем бәхетем юк инде...

Безнең алга бик зур флаг тоткан бер апа килеп басты.

Инде кузгалып киттек дигәндә генә, баягы пионер кыз килеп җитте. Ул кулына озын саплы чын флаг тоткан. Флагы бик зур түгел, шулай да чын.

— Ә сиңа иң матурын бирәм. Кара әле, кара ничек җилферди бит,— ди апа. Үзе флагның сабын миңа тоттыра.

Мин тиз генә флагның сабын эләктереп алам, үзем югарыга карыйм. Баш өстемдә кызыл ефәк кош шикелле, талпынып тора. Әйтерсең ул кызыл кош биеккә, әллә кайларга очып китәргә тели. Үзе мине дә күтәреп алырга тырыша кебек. Әгәр флаг мине күтәреп алып китсә, мин иң элек әтием янына барып төшәр идем дә фла-

гымны атының иярenә кадап куяр идем. Шуннан соң без этием белән икәүләп фашистларны җиңеп бетерергә атны җилдереп кенә китәр идек. Кызыл флагтан фашист куркып качар иде.

Ә соң шушы бөтен халык очып кына дошман алдына барып төшсә, куркудан йөрәге ярылыр иде тегенең. Ә дуслар инде шатланып туя алмаслар иде. Дуслар үзләре дә безгә кушылып китсә, тагын да күбрәк булырбыз...

Оксана минем җиңемнән тарта. Байрак тотып торган апалар алга ук киткәннәр, бөтен халык кузгалган, мин берүзем кала язганмын. Ярый минем сеңелем бар әле.

Мин атлый башлагач, флагым тагын да ярсыбрак талпынырга тотынды.

Без инде урам буйлап барабыз. Безнең якьяктагы өйләр дә, канау буендагы яңа гына бөреләнеп килгән агачлар да, янымдагы балалар да миңа бәләкәйләнеп киткән төсле күренәләр. Әллә мин үзем шулай кинәт кенә үсеп киттемме икән? Мин атлап барган да төсле түгелмен. Чынлап та, кулымдагы флаг, кызыл флаг, мине очыртып кына алып бара, ахры.

Артта җыр башладылар. Минем дә ул җырны ишеткәнем бар. Ләкин бу юлы ул әллә кайдан, ерактан яңгырап килгән кебек тоела.

Минем дә җырга кушыласым килә. Тик нигәдер тавышым тамагым төбеннән тышка чыкмый кала. Күз кырыем белән генә Оксанага карап алам. Аның да иреннәре кыймылдый. Артта яңгыраган җыр, әйтерсең бөтен байракларны да җилфердәтеп, баш өстеннән агып үтә. Мин башымны тагын да югарырак күтәрәм. Флагым җыр көенә тирбәлеп бара.

Оксана минем беләгемнән тота:

— Җырла, Җәмил, рәхәт бит.

— Әйе, әйе, Оксана, бик рәхәт,— дип пыщылдыйм мин. Сеңелем миңа иелә төшеп җырларга тотына.

Җырлыйк без иң бөек кешегә,
Атабыз Сталинга дан җырын...

Үзебезнең капка төбенә җиткәч, дәү әниемне күреп калдым. Ул койма янына баскан да үткән кешеләргә карап елмаеп тора. Ул, бәлки, безне эзлидер әле. Без, аяк очларына басып, аңа күренергә тырышабыз:

— Дәү әни! — дибез.

Оксана белән мине күргәч, аның йөзе тагын да ачылып китә. Дәү әнине күргәч, минем исемә башмаклар килеп төшә. Мин түбән карыйм. Оксана белән икебезнең дә яңа башмаклар кигән аякларыбыз туп-туп басып килә. Инде җыр да ерактан ишетелгән кебек түгел. Хәзер мин үзем дә җырга кушылам, һәм бөтен урамны гөрләткән җыр әйтерсең бер минем күкрәгемнән генә чыга — мин шулай кычкырып җырлыйм. Әнә өйләр дә, агачлар да элекке кебек кенә күренәләр — кечкенә дә түгел, зур да түгел. Тик аякларым белән җиргә басканымны гына сизмим.

Мин янымдагы теге, арткы урам малаена карыйм. Аның кечкенә генә борыны өстендә бөрчек-бөрчек тир ялтырап тора. Атлаган саен үзенең итләч бите дер-дер калтырап китә. Миңа кызык булып тоела. Нигә аның гына бите шулай селкенә икән.

Тиз генә сеңелемә дә күз салып алам. Ул туп-туры алга карап атлап бара. Аның зәңгәр күзләре чак кына кысыла төшкәннәр, ә кулындагы кечкенә генә флагы җилфердәп, коңгырт чәчләренә тиеп-тиеп китә. Үзе нигәдер әзрәк тур-

сайган да төсле. Кинәт минем колагыма кемдер пышылдаган кебек була. Юк, берәү дә пышылдамый — мин үзем эчтән генә шулай уйлыйм: „Сиңа, Җәмил, чын флаг тоткач, бик рәхәт бит. Барысына караганда да рәхәтрәк. Аларның чын флаг тотасылары килмидер шул?..“ Мин барысына да: Оксанага да, Фәриткә дә, Фәһимәгә дә, арткы урам малаена да бик-бик рәхәт булуын телим. Тотам да хәзер флагны башта сеңелемә бирәм. Ул чак кына баргач, флагны Фәриткә бирер, шуннан соң кулдан кулга китәр ул флаг. Нинди яхшы булып чыгар.

Мин, сеңелемнең җиңеннән тотмакчы булып, кулымны сузам, тик шунда ук тукталып калам: ә әнием безгә укыган кызыклы китапта ничек иде соң? Андагы бер солдат сугышта яралангач та үз кулындагы байракны ташламаган да, берәүгә дә бирмәгән дә. „Байрак ул изге әйбер“,— диде миңа әнием. „Изге“ — ул үтә әйбәт дигән сүз. Байрак ни, флаг ни — икесе дә бер үк инде. Бәлки, минем кулымдагысы да байрактыр әле.

Мин флагның сабын тагын да кысыбрак тотам. Җыр тынган арада аның кыштырдавы да миңа ишетелеп китә. Юк, флаг кемгә бирелгән, шуның кулында калырга тиеш ул. Бирсәм, теге пионер апага гына бирермен.

Алдагы апа Тимербулат бабайлар тыкрыгыннан Кыр ягына борылды. Без барыбыз да Кыр ягына чыктык. Сай чокырга җитәрәк бер таш өеме янында бөтен халык туктап калды. Шунда гына баягы пионер апа килеп минем флагымны алды. „Кулың талгандыр инде, туганым“,— диде ул. Ә минем кулым чак кына да талмады. Флаг тоткан кешенең кулы таламы икән? Бармакларым гына оеды. Анысы исәпкә дә керми инде.

Зурлар барысы да таш өемен уратып алды-

лар. Рәшит абый таш өстенә менеп басты. Мин аны чак кына күреп калдым. Кайдандыр Марат килеп чыкты.

— Әллә-лә-лә, болар чын флаг тотып бардымыни! — диде ул. Шунда минем иңбашка кулын салды. — Әллә көнләште дисеңме? Көнләшмәдем дә, күз генә кызды азрак.

Мин бернәрсә дә әйтеп өлгерә алмадым, сеңелем килеп җитәкләп алды:

— Әйдә, әнине табабыз, Җәмил, — диде ул. — Син чын флаг тотып баргач — нинди яхшы булды. Әни дә, дәү әни дә, Мансур бабай да шатланыр әле. Мин дә шатландым. Әйдә инде.

Без халык артында җитәкләшеп йөгереп йөргәндә, кемнеңдер куллары икебезне берьюлы кочаклап алды. Бу әни иде. Ул Оксананы җиңел генә итеп күтәрде дә иңбашына утыртты. Шунда ук мине дә бер абый эләктереп алып җилкәсенә атландырды. Мин очып кына килеп кундым. Хәзер Оксана белән икебезгә бөтенесе дә күренеп тора. Таш өстенә баскан Рәшит абый кулындагы фуражкасын болгый-болгый сөйли. Фуражкасындагы йолдызы, көзге кисәге кебек, кояшта ялтырап-ялтырап китә.

— Яшәсен безнең партия! — ди Рәшит абый, үзе таш өстеннән сикереп төшә. Бөтен кешеләр дә „ура“! кычкыралар, үзләре кул чабалар. Оксана белән без дә кул чаптык.

Безне җиргә төшерделәр.

— Арыгансыздыр инде, балалар, барыгыз, кайтыгыз, — диде әни. — Ә син, кызым, флагыңны миңа бир, апаңа мин үзем бирермен, яме.

Без йөгереп кайтып та киттек. Тыкрыкка кергәндә без артыбызга әйләнеп карадык. Бөтен кешеләр дә җырлашып кайтып киләләр иде инде.

Нәрсәләр белән генә сыйламады безне дәү әни ул көнне! Безне дә, бәйрәмне дә ярата бит ул. Нәрсәләр белән сыйланганыбызны сезгә әйтә алмыйм инде. „Мин тегене ашадым, мин моны ашадым дип сөйләп йөрү бер дә килешә торган эш түгел“, — ди дәү әни үзе. Юк, ул сүзләрне безгә әйтми, әллә нинди бер апага әйтә. Ә без сөйләнеп йөрсәк, безгә дә әйтер.

Нәкъ шушы көнне инде мин сеңелемне бакчадагы каен төбенә алып килдем. Теге элек әйткән хәзинәне казып алып, барысын да аңа бирдем. Матур тәтиләр белән әйбәт ташлар гына өч кесә булды Калганы барысы да тимер заты иде. Алары Оксанага ошап җитмәде. Ярый, торсын әле ул тимерләр. Мин соңыннан берәр нәрсә эшләрмен алардан...

БЕЗНЕҢ ӘТИНЕ КҮРМӘДЕГЕЗМЕ?

Бераздан соң тагын бәйрәм булды. Бу үзенә башка бер бәйрәм иде.

— Сугыш бетте, без җиңдек! — диделәр зурлар.

Халык тагын клуб янына җыелды ул көнне. Без дә Маратлар, Фәһимәләр белән шунда бардык. Безнең очта торган матур укытучы апа сүз сөйләде. Әбиләр дә, апалар да үзләре көләләр, үзләре елыйлар. „Алар нигә елыйлар, Мансур бабай?“ — дип сорыйм мин. „Шатлык яшьләре, балам, алар, татлы яшьләр“, — ди ул. Шулай дигәч, минем дә елыйсым килеп китте, ләкин түздем, чөнки минем кебекләрдән берәү дә еламый. Андый татлы яшьләр, бәлки, апалар белән әбиләрдә генә буладыр. Әкияттәге Тимербәк тоткын кызларны коткаргач та, шатлыкларыннан елашып алганнар бит тегеләр.

Оксананы бер апа күтәреп ала. Үзе сөйләнә: „Бик бәхетле булырсыз инде, балакайларым, әнә нинди аждаһаны дөмектерделәр бит...“

Кичкә каршы без Мансур бабай белән Фәрхениса әбине чәй эчәргә чакырдык. Үзебез караңгы төшкәнгә кадәр урамда йөгереп уйнадык. Зурлар да бертуктаусыз җырлашып, биешеп кенә тордылар. Кешеләр шат булсалар, җырлыйлар шул. Әнием дә этидән хат килгән көннәрдә җырлап куя торган иде. Нинди яхшы — кешеләр шат булгач!..

Ул чакта әле шомыртлар белән алмагачлар яңа гына чәчәк аткан иде. Шул көннән алып без өчебез дә этине көтә башладык. Хәзер инде безнең колхозда печәнне бетереп, уракка төштеләр. Ә эти һаман кайтмый да кайтмый. „Тиздән күрешербез“ дигән хаты килүгә дә әллә ничә көн булды инде. Әни эштән кайткач, төн буе өйнең стеналарын юды, мичне ап-ак итеп агартты, без өчәүләп ишек алдын себердек. Анда хәзер бер генә чүп тә юк.

Оксана белән без әллә ничә кат инде авыл очына чыгып та көтеп карадык. Тик эти һаман кайтмый. Шулкадәр озак кайтмый торган кеше булыр икән.

Бервакыт, әнием төшкә кайткач, безгә Тәзкирә апа керде.

— Беләсеңме, Көнбикә җиңги, күпер башы Бәкернең Рамазаны кайткан бит, башкалар да озакламас инде, — ди ул.

— Указ булуга да шактый вакыт үтте шул. Безнеке бит җитмәсә дүрт тапкыр яраланган да, — ди әнием.

Мин Указның нәрсә икәнен генә белмим. Тик, эти кайтуга катнашы булгач, яхшы әйбердер дим. Оксананы ымлап кына чакырып алам да, без болдырга чыгабыз.

— Ишеттеңме? — дим мин.

— Нәрсәне?

— Күпер башын. Әйдә шуларга барып кайтабыз.

Мин әйткәч, сеңелем карышып тормый. Без капка астыннан гына чыгып, түбән очка йөгерәбез. Хәйбулла Рушаны безне күрми дә калды. Күрсә дә, хәзер таш ыргытмый инде ул. Оксананың башмагын агызып җибәргәч, Рушанның усаллыгы бетеп китте. Беркөн бит без, каз саклаганда, Рушанны пленга алдык та Фәһимәнең косынкасы белән кулын артка бәйләдек. Шуннан аны әйбәт булырга ант иттердек. Ант итте теге. Марат үзен кыйный да язып куйды. „Бәхетең инде, сугыш бетү шатлыгыннан бер юлга калдырам“, — диде. Шуңа күрә без аны пленнан да коткарып җибәрдек. Хәзер Рушан әйбәтләнде.

Күпер башы Бәкер абыйларны беләм мин. Алар почта йортына якын гына торалар. Аларның рәшәткә белән уратып алынган зур бакчалары бар. Әле дә анда кызарып кына килгән алмалар асылынып-асылынып тора. Почтага барганда үзебез күрдек.

Оксана белән без икәү, Бәкер абыйларның капка төбенә барып җиткәч тә, туктап калдык. Капка ачык. Әллә ул ачык булганга инде без керергә кыймый торабыз. Мин, башымны тыгып, өй алдына карадым.

— Кем анда капкага сыймый тора? — диде бер калын тавыш. — Әллә зурысын ачаргамы?

Мин каушап калдым. Кире кайтып китәргә дә уйлаган идем — теге тавыш йомшак кына итеп тагын эндәште:

— Керегез, балалар. Кунакка килгән кеше шунда тормый инде ул.

Без җитәкләшеп өй алдына кердек. Болдырда бер солдат абый итек чистартып тора. Үзе безгә карап елмая. Итеген ышкыганда аның күкрәгендә тезелеп торган медальләре чыңлап китә. Мин Оксананың колагына пышылдап алам: „Шушы үзе инде“, — дим. Солдат абый инде итек чистартудан туктый.

— Әйдүк, ни йомыш, туганнар? — дип сораша ул.

Мин каушавымнан:

— Бер йомыш та юк, — дип әйтеп салам.

Оксана кинәт минем җиңемнән тарта.

— Җәмил оныткан, абый, безнең йомышыбыз бар, — сеңелем үзе бер адым алга атлап куя. — Безнең әтине күрмәдегезме? Кайчан кайта ул?

— Кем соң сезнең әтиегез?

— Кавалерист. Аның да өч медале бар.

— Алай булгач, беләм, — ди абый, үзе рәхәтләнеп көлә, фашистны җиңүгә шулай шатланадыр инде, — тик кайткан чакта гына күрә алмадым шул. Озакламас инде, ул да кайтыр.

Нәкъ шушы минутта әти өйгә кайтып кергәндәй була миңа. Ә чынлап та шулай булса?

— Без кайтабыз инде, абый, — дим мин, тиз генә сеңелемне җитәкләп алам.

— Туктагыз әле, туктагыз, — дип, абый минем беләгемнән тота, үзе ачык тәрәзә ягына карап кычкыра: — Әни, монда ике кунак бар, күчтәнәч чыгарыр иден...

Матур яулык бәйләгән әби икебезгә икешәр дәү чикләвек белән берәр конфет бирде. Без рәхмәт әйттек.

Солдат абый һаман сорашып тора:

— Сез игезәкләрме әллә, бигрәк тип-тигезсез?

— Юк, игезәк түгел, — дип җавап бирәм мин, — без болай гына ике туган, абый.

Шунда ук чыгып та йөгерәбез.

— Мин мондый солдатларны бик күп күргәнем бар, — ди сеңелем.

— Кайда?

— Сугыш булган җирдә, бик еракта. Әти мине кочаклап-кочаклап яраткан төштә.

Оксана кайсы вакытта шулай кызык сүзләр сөйләп куя. Кечкенә кеше сугыш булган җирдә йөриме инде? Ләкин мин бәхәсләшмим. Я ул үпкәләр.

Без үз өебезгә кайтып җитәбез. Әни, ишек келәсенә агач кына тыгып, эшкә киткән. Ә әти һаман да кайтмаган.

* * *

Көн саен кешеләр фронттан кайтып торды. Марат белән Фәһимәнең әтисе дә, Бадамша бабайның зур улы да, арткы урам кешеләре дә кайтты. Без Оксана белән икәү аларның барысына да барып, әтине сорашып йөрдек. Тик барыбер „күрдем“ дип ачык кына әйтүче булмады. Кайсы әти турында ишеткән, кайсысы ерактан гына күреп калган, кайсы аның турында газетада язылганны укыган.

Без көннәр буе станция юлыннан күз дә алмыйбыз. Берәр кеше күренсә, йөгереп каршы барабыз. Ә әти юк та юк.

Әтине көтә башлаганда каз бәбкәләре кечкенә генә иде. Алар инде үсеп җитте. Арада иң матуры — теге мин эчемнән генә „Оксана“ дип исем кушканы. Ата каз безне таласа да, аларның балаларын барыбер яратабыз. Көн дә жим биреп торабыз. „Әти кайтканчы үсә торсыннар!“ — дип,

алмагачларга көн дә су сибәбез. Алар чәчәк атмадылар әле атуын, күп иттереп яфрак кына ярдылар. Ә мәкләрнең чәчәкләре коелып бетте инде... Менә никадәр вакыт үтеп китте. Безнең башмакларыбыз гына шул көе тора. Аларны бит кимибез, әти кайтуга саклыйбыз.

Кич яткан саен без кровать турысында элеп куйган рәсемгә карыйбыз. Оксана куллары белән аны үзенә чакыра:

— Кайт инде, әти, кайт! — ди.

— Бәлки, безнең әти дошманны иң еракка кадәр куып баргандыр, шуның өчен тиз генә кайта алмыйдыр, әйе бит, Оксана?

Сеңелем, „әйе“ дип, иснәп ала да шунда ук йоклап китә.

Тизрәк иртә булсын иде дә әти кайтсын иде, дип уйлыйм мин кич саен... Безгә карап, әни еш кына көрсенеп куя.

ТӨШ ТӘ, ӨН ДӘ

Өндә сурәтләр сөйләшми бит. Ә төштә алар сөйләшәләр дә, көләләр дә. Мин сурәт турында төш күреп ятам. Менә, имеш, әтинең кровать өстендә эленеп торган сурәте стена буйлап шуышып кына минем янга төште. Үзенең аяклары да, куллары да бар. Авыз читләре буйлап асылынып төшкән мыегы кыймылдап тора, күкрәгендәге медальләре чыңлап-чыңлап китә. Ул шундый ачык итеп елмая, аның күзләреннән чәчелеп торган яктылыкка минем күзләрем чагыла. Сурәт үзе кем беләндер әкрен генә сөйләшә дә төсле. Мин күзләремне ачмакчы булам, тик нигәдер алар башта тиз генә ачылмыйлар. Эндәшмәкче булсам, тавышым чыкмый. Нинди әкәмәт төш күрәм мин?

Кинәт күзләрем үзләре ачылып китте. Өй эче шундый якты, кояш нәкъ Оксана белән миңа карап тора. Ә сурәт, нәрсә эшләптер, икәү булып китә, берсе яңадан стенага барып эленә, икенчесе — терескә һаман минем янда басып кала. Кинәт ул мине күтәреп алып күкрәгенә кыса. Мин инде бөтенләй уянам. Безнең янга әни дә йөгереп килә. Әни еш-еш итеп нәрсәдер әйтә. Мин аның сүзләрен аңламыйм, үзем, башымны аның иңбашына салып, әтинең битләрен сыйпыйм.

— Әти! — дип кычкырып җибәрәм. — Нигә шулкадәр озак кайтмый тордың, әти?

Әти мине күтәреп тора. Мин Оксанага карыйм. Ул, нәрсәдәндер сискәнеп, торып утыра. Әти шунда ук икенче кулы белән сеңелемне күтәреп ала:

— Менә кызым да уянды. Таныйсыңмы мине, кызым?

Оксана көлеп җибәрә һәм әтине үбеп ала. Ә мин аны үбәргә дә оныттым.

— Әти! — ди сеңелем, — без сине көттек тә көттек.

— Сез көткән өчен дә исән-сау йөреп кайттым бит инде, бәхетегез бар икән, балалар, — ди әти. Үзе, икебезне дә күтәргән көе, сандык өстенә барып утыра.

Мин аның медальләрен санап карыйм: бер, ике, өч, дүрт, биш... Тик күлмәгенең сул кесәсе

өстендәге ике сары, ике кызыл тасманың гына нәрсә икәнен ул чакта белмәдем. Ә хәзер беләм. Улмы? Ул — безнең әти дүрт тапкыр яраланып, дүрт тапкыр сәламәтләнгән дигән сүз.

Без сандык өстендә шулай бик озак утырдык.

Оксана кайтканда да безгә кеше бик күп килгән иде бит, ә бу юлы тагын да күбрәк килде. Кайсылары әти белән ике куллап күрешәләр, кайсылары бер куллап күрешәләр. Әби кешеләр аның аркасыннан да сөеп алалар. Мансур бабай да кереп әзрәк утырып китте.

— Изге эш башкарып кайттыгыз, бик зур рәхмәт инде, — ди ул. — Җимерелгәне төзәлер, тузганы яңарыр, тик әнә ятимнәр генә бик кызганыч.

Әти тирән көрсенеп куя. Мансур бабай шунда ук икенче нәрсә сөйли башлый:

— Безгә дә кыен булды, иллә мәгәр бирешмәдек, бернинди эш тә карышып тормады, үзең дә күрерсең...

Безнең кебекләрдән иң элек Марат белән Фәһимә килеп житте. Алар бу юлы әллә нигә ишек янагына сөялделәр дә каттылар. „Узыгыз, түргә узыгыз", — дисәк тә, урыннарыннан кузгалмадылар. Беләм инде, алар әтиемнән оялалар.

Заман барыннан да соң килде, тик ул ишек төбендә туктап калмады, туп-туры әтигә килеп сарылды. Әтием Заманны күтәреп алды. Ә тегесе әтинең муенныннан кочаклады да үбәргә тотынды. Без аптырап карап торабыз.

— Иң сагынган кеше менә кем икән! — ди әти.

— Мылтыгың булса, ат әле, абый, — ди Заман.

— Монда бит фашист юк.

— Син тилгәнгә ат, ул бүген бер зур чебешне урлап китте.

Бөтен өй эче гү килеп көлеп җибәрде. Заман һаман үзенекен сораша:

— Кылычыңны күрсәт әле миңа.

— Кылычны алып кайтмадым шул, балакай. Менә шәһәргә баргач, мин сиңа кечкенә кылыч сатып алырмын, ямме?

— Ярар, кечкенә булса да...— дип, Заман әтинең кочагыннан шуып төшә. Үз өлешенә тигән күчтәнәчне алгач, ул чыгып ук йөгерә.

Марат белән Фәһимә безне уйнарга чакыралар. Без әтинең бер үзен генә калдырып барыбер чыгып китмибез.

Әнием ул көнне эшкә бармады. Кичкә кадәр мич янында төрле тәмле әйберләр пешереп йөрде. Без һәрвакыт әтигә сыенып кына тордык. Әни дә безнең янга килгәләп китә. Ул бер әтигә, бер Оксанага, бер миңа карый, үзе өзлексез елмая. Сөйләгәндә сүзләре дә, чулпы чылтыравы кебек, матур булып чыга. Әниемнең янып торган ал йөзендә ниндидер нур балкыган төсле тоела миңа. Әйе, мин күреп торам, ул нурлар әниемнең күзләреннән бөркелеп чыгалар да йөзенә таралалар. Бер аның йөзенә генә түгел, бөтен өйгә, бөтен урамга тарала ул нурлар. Теге чакта, аркасына капчык асып, калын ак шәлен ябынып, кышкы төндә ерак шәһәргә киткән әнигә бер дә охшамаган ул бүген. Ә үзе шул ук безнең әни.

Төштән соң Тимертаудагы дәү әни дә килеп җитте. Без, аның капкадан кергәнен күреп, йөгереп каршы чыктык.

— Һай, зирәкләрем,— ди дәү әни, үзе, икебезне дә җитәкләп, бер йөгереп — бер атлап өйгә кереп китә. Без бу юлы аның камзул кесәсен дә актармадык.

Дәү әни үзе әтиемне сөя, үзе акрын гына елый.

— Беләсеңме, Оксана, дәү әнинең күзеннән чыккан яшьләр — шатлык яшьләре, татлы яшьләр алар, — дим мин.

— Ә син кайдан беләсең?

— Мансур бабай әйтте.

— Чак кына да бирешмәгәнсең бит, инәй, Тимертауныкы булгач та, әллә тимер кеше инде син, — ди әти дәү әнигә.

— Тимер дә тутыга, балакай, бу авыр көннәрдә тимердән дә нык булырга кирәк иде шул.

Мин пырхылдап көлеп җибәрәм.

— Нигә көләсең? — дип сорый Оксана.

— Дәү әнинең куллары йоп-йомшак, үзе тимердән дә каты, имеш.

Минем дәү әнидән көлүем Оксанага ошамый. Ул кашын җыерып куя.

Төшке чәйне эчеп беткәч, әти каешын буды, пилоткасын киде.

— Әнисе, — диде ул, — без балалар белән бергәләп яланнарны әйләнеп кайтмакчы булабыз. Исән кайтсам, аркамдагы капчыгымны да салмый, яланнарны, тугайларны урап чыгармын, дигән сүзем бар иде... Әллә безнең белән үзең дә барасыңмы?

— Бу юлы үзегез генә йөреп кайтыгыз. Бер дә генә бушамыйм шул, — ди әни, үзе Оксана белән минем яланаякларыбызга карый. — Ә сез ни эшләп башмакларыгызны кимәдегез?

Менә сиңа кирәк булса! Әти кайткач башмакларны бөтенләй онытканбыз. Мин шунда ук кровать астына тәгәрәп кереп китәм дә башмакның дүртесен берьюлы алып чыгам.

— Менә, әти, дәү әнинең бүләге — кызыл чуклы сары башмаклар, — дим мин.

— Минем бер башмак Көмешледә агып киткән иде әле, Җәмил табып алып кайтты, — ди сеңелем.

— Балыкчы Яхшыгол бабай белән икәүләп тоттык.

— Ул башмаклар шатлык та, кайгы да булды инде, — ди дәү әни. — Син кайтканчы кидерә алмадык: „Әти кайткач, киябез“, диделәр. Әле бөтенләй исләреннән дә чыккан. Әй, балалар, балалар...

Без башмакларыбызны киеп җибәрәбез. Шуннан соң өчәүләшеп, мунча яныннан гына үтеп, Кыр ягына чыгабыз. Без Оксана белән икебез әтинең ике ягыннан йөгерәбез. Ә ул хуш исле үләннәрне өзеп ала да, борынына китереп, иснәп тора, кояшта кызган чакма ташларны алып, әкрен генә яңагына ышкый. Я ул безнең белән бергә йөгереп, тирән чокырларның төпләренә төшә дә, чәнечкеле көрән чәчкәне өзә, яисә берәр таш өстенә басып, озак итеп бөтен тирәякны карап тора. Без инде сай чокырны да үттек. Әти безне каенлык урманының теге башындагы чишмә янына алып килде. Әй салкын ул чишмәнең суы. Әти чишмәдә кулларын, битләрен юды, аннан, учлары белән алып, су эчте. Без дә эчтек. Шуннан өчәүләп үлән өстенә утырдык.

— Бу чишмәне сезнең дәү әтиегез — минем әтием Батырша казыган иде, — ди әти. — Мин ул чакта сезнең кебек кенә идем. Шуннан бирле „Батырша чишмәсе“ дип йөртәләр. Ә күпме кеше су эчкән, битен юган шунда... Кошлар да, җәнлекләр дә килеп су эчеп китәләр... Әнә карагыз, аның тирәсендәге кызыл чәчәкләр ничек рәхәтләнеп үсеп утыралар.

— Рәхмәт инде дәү әтигә, — ди Оксана. Әти

аны, кочагына алып, маңгаеннан үбә дә тагын җиргә бастырып куя.

— Дөрес, кызым! Нинди акыллы бит минем кызым.

— Әти, — дим мин, — әти, әйдә без дә өч чишмә, юк, дүрт чишмә казыйбыз: сиңа, әнигә, Оксанага, миңа. Безгә дә рәхмәт әйтерләр.

— Сез, үскәч, кечкенә чишмәләр генә түгел, зур күлләр ясарсыз, зур елгаларның агышын борырсыз, ди әти. Кешеләргә файдалы тагын бик күп эшләр эшләрсез.

— Ярый, — дип, мин баш иям. Тик үзем хәзергә зур күлләр дә, зур елгалар да ясый белмим. Үскәч белермен әле, әти үзе өйрәтеп бирер.

— Мин дә ясашырмын, әти, ярармы? — ди сеңелем.

Әти утырып тора, үзе безгә кулларын суза, без сеңелем белән икәү аны кулларыннан тартып торгызабыз.

— Хәзер инде Имәнле күл буйларына барып чыгыйк. Арымадыгызмы? — дип сорый әти.

Без тамчы да арымадык әле. Әти кайткач, арыта диме инде? Без, авыл очын кире урап, Көмешле тугаена чыгабыз.

Имәнле күл буенда тукмак башлы бернәрсә үсә, үзе матур, үзенең мамыклары очып тора. Аның исеме — зикән. Күл буена баргач, без аларны күп иттереп өздек. Төнбоек яфраклары да җыйдык. Ук ясарга төз камышлар алдык. Без анда зур үрдәкләрне дә, бәләкәйрәк үрдәкләрне дә күрдек. Алар бездән куркып очып киттеләр. Ә бакаларны күрсәк тә әйтеп тормыйм. Яратмыйм мин ул бакылдыкларны.

Шуннан соң әти безне әллә нинди сукмаклардан алып китте дә кайтыр юлга чыгарды. Тугайдан кайтканда бер тауны менәргә кирәк.

Без чак кына арыган идек тә, бер агач төбенә утырып ял иттек. Тагын да әтинең медальләрен тотып-тотып карадык. Шуннан соң ул ике түгәрәк медальне кулмәгеннән ычкындырды да безнең күкрәкләргә кадап куйды. Шунда ук безнең аруыбыз бетеп китте. Сугышта медаль алгач, әтинең аруы да шулай беткәндер әле. Менә нинди яхшы бит ул медаль.



Тауны инде без тиз генә мендек. Тау башына ук җиткәч әти тагын тукталды. Моннан безнең авылның өч урамы да, Көмешле буйлары да, теге Имәнле күл дә, куксел урман читендәге Тимертау да күренеп тора. Мин аптырыйм: безнең урманнар барысы да яшел, ә Тимертау урманы куксел. Дәү әни белән барып карармын әле мин ул урманны...

Ерактагы тау яныннан, озын төтен чыгарып, поезд үтеп бара. Якын басуда комбайн бодай урып йөри, аның өстенә бәләкәй генә кеше ме-

неп баскан. Әллә минем кебек кенә берәр малаймы икән ул?

Әти, кулларын кашлары өстенә куеп, озак итеп карап тора.

— Менә, балалар, — ди ул, — болар барысы да сезнең туган җирегез. Әнә теге таулар, урманнар, елгалар артындагы да, бик ерактагы да сезнең туган җирегез. Әле сез күрмәгән, сез белмәгән җирләр бар. Әнә шул җирләрдән дә куып җибәрдек без фашистларны. Аңлыйсызмы?

Без барын да төшенеп җитмибез. Тик әтинең бик яхшы сүзләр сөйләгәнен аңлыйбыз. Ә үскәч, әти сугышып йөргән якларны барып күрербез дә, барысын да аңлап кайтырбыз.

— Ә сагынуның нәрсә икәнен беләсезме? — ди әти.

— Нәрсә соң ул?

— Сезнең мине күрәсегез килдеме?

— Әй озак тордың, әти, без елап беттек, — дип Оксана аны кочаклап ала.

— Менә минем дә шулай сезне дә, шушы урманнарны да, чишмәләрне дә, юлларны да күрәсем килде.

— Ә син еладыңмы, әти? — дип сораша сеңелем.

— Юк, кызым, елавын еламадым. Елыйсым килсә дә — түздем.

— Ә нигә түздең?

Оксана шуны да белми. Солдат кеше елап тормас инде.

Безнең арттан сакаллы бер абый килеп җитә.

— Сау гына кайттыңмы, исән генәме, йортҗир иминме, туган?.. Сәхрәгә чыктыңмы? Ярый, ярый, бик әйбәт. Күркәм эш. Сагындыргандыр шул. Әйе, ярый, ярый, бик әйбәт, — дип сөйләргә тотынды. Үзе әтинең кулын тоткан да җибәрми.

Әти нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачкан

иде, теге абый аның сүзен тыңламый, тагын сөйләп алып китте:

— Нигә, шунда бер чыккач безнең яшелчә бригадасы янына да барып житмәдең? Карбыз белән сыйлар идек. Әйе. Помидорлар котырып унды быел. Менә һич арттыру булмас, куш йодрыктан һич кайтыш түгел. Балаларыңны да алып төш. Нинди үскәннәр икән, тфү, тфү, күз тимәсен... Кабаклар мичкә кебек тәгәрәп яталар, носилка белән ташырга туры килер инде. Бар, ярыймы! — диде ул, үзе вак-вак атлап китеп тә барды. Бу абыйның аяк атлавына күз дә иярми, үзе бәләкәй генә, үзе нинди кызу йөри. Эше күптер шул.

Әти аның артыннан елмаеп карап кала:

— Һаман шул Җантүзмәс-Гәрәй икәнсең, — ди ул теге абый турында.

Без кайтырга кузгалабыз. Җантүзмәс-Гәрәй абый, кинәт кире борылып, безгә каршы йөгереп килә:

— Гаепкә алма, туган, — ди ул, — ниндирәк эшкә тотынмакчы буласың—агынамы, карасынамы дигәндәй? Әгәр ашыгыч димәсән, минем бригадада бик әйбәт аклы-каралы бер эш бар. Шәһәргә җимеш сатуны юлга салып җибәрер идең. Әйе.

— Син дә гаепкә алма, Гәрәй абый, мин шул ат тирәсенә барырмын инде дип торам.

— Бигайбә, — ди Гәрәй абый, — үзең беләсең.

Ул янадан безне артта калдырып китә.

Без урам башына килеп житәбез. Читтән дүртенче өй, әнә теге өй, безнеке инде.

* * *

Менә күрдегезме инде — дүртенче алмагачның да иясе булды. Әтине әйтәм. Мин дәү әнине

исәпкә кертмим. Ул бит Тимертаудан кунакка гына килеп йөри. „Ни өчен мине исәпкә кертмисең?“ — дип ачуланмый ул, безнең дәү әни. Нигә, кунак булып тору яхшы түгелмени?

Мин барыбыз турында да сөйләп бетермәдем әле. Тик сез ашыкмагыз. Бер сөйли башлагач, мин тукталып кала торган малай түгел. Үзебезнең өй, бигрәк тә сеңелем турында сөйләргә мин бик яратам. Тик сүземә колак салучы гына булсын. Сез дә тыңлый башлагач, ярты юлда тукталып калмагыз. „Ярым-ярты эш эшләп йөрү — ирлек түгел“, — диде Мансур бабай беркөн чокыр буе Заһитка. Заһиты да бит ярты бакчасын киртәләгән, яртысын киртәләмәгән.

Ягез, алайса тыңлагыз, сөйләп бетерәм.

БЕЗ ТИЗДӘН МӘКТӘПКӘ БАРАЧАКБЫЗ

Әти кайткач мин сигезгә чыктым, ә Оксана һаман җиде белән бара.

— Балаларга сабакка йөрергә кирәктер бит инде быел, — диде әти беркөнне иртән, атлар яныннан кайткач.

— Үзләре бер дә сүз кузгатмыйлар бит әле. Әллә укыйсылары килми инде, — ди әни. Беләм инде, ул шаярып кына шулай әйтә. Кинәт шул вакыт әни кыш көне җибәргән теге телеграмма хәтеремә килеп төште. Дәү әни белән Мансур бабайның язуны таный торганнарын, Мәхмүтнең эре генә кыланып укып төшендергәнен уйладым. Әни аларны белми шул, ә мин беләм. Белсә, ул шулай шаяртып тормас та иде.

— Безнең укыйсыбыз бик килә, әни, — ди сеңелем. — Сентябрь булгач та, күмәкләп мәктәпкә китәрбез.

Ә мин һаман эндәшмим, теге телеграмманы уйлап утырам.

— Син соң, Җәмил, ничегрәк уйлыйсың?— моны әти сорый. Ничек уйлыйм ди мин? Укырга уйлыйм.

— Укырга уйлыйм, әти,—дим мин кычкырып.—Сентябрь генә тизрәк булсын...

Мәктәп турында башкача сөйләшмиләр.

Әти белән әни эшкә киткәч тә, без икебез болдырга чыгып утырабыз. Арткы урамның теге очындагы ак зур мәктәп безгә күренеп тора. Сентябрь җиткәч, без, Оксана белән икәү, китапларыбызны күтәреп шушы болдырдан төшәрбез. Аннан урамга чыгарбыз да ән-ә-ә теге юл белән китәрбез, шуннан мәктәпкә дә барып җитәрбез.

— Без анда язу да язарбыз, сурәтләр дә төшерербез. Мин чәчәк төшерермен, ярыймы, Җәмил.

— Мин — ат та мылтык...

— Матур җырлар җырларбыз. Син башларсың, яме?

— Укытучы апа башласын...

Нәкъ шул вакытта үземнең җырлыйсым килеп китә. Еракталы ак мәктәпне, аның тәрәзәләрен, мәктәп янындагы зур агачларны, агачлар яныннан үткән юлны күреп торсагыз, өстәвенә шул юлдан үзегезнең дә шул мәктәпкә барачагыгызны уйласагыз, беләм, сезнең дә җырлыйсыгыз килер иде.

Мин җырны башлап җибәрәм:

Тау башында ак мәктәп,
Без барырбыз күмәкләп...

Сенелем ялт итеп миңа әйләнеп карый. Ул, үзенең зәңгәр күзләрен кыса төшеп, шунда ук

җырга кушыла. Безнең аякларыбыз да тик кенә тормыйлар, җыр уңаена селкенергә тотыналар

Китаплары — шау сурәт.
Мәктәп, син безне өйрәт
Укырга, язарга,
Рәсемнәр ясарга.

Безнең капка астыннан Фәһимә үрелеп карый. Без җырдан туктыйбыз. Шул арада Марат коймага менеп атлана. Безне күргәч, Фәһимә йөгереп килә.

— Җыллашып утыламы ни беләүләл, — ди ул. Һаман бетми шул Фәһимәнең сакаулыгы.

Марат сыбызгысын сызгыртып җибәрә, үзе, кулын болгап, безне урамга чакыра. Оксана өй ишеген ябып куя. Ишекне япмый китсәк, тавык чебешләре өйгә керә дә тула. Тәрәзә төпләренә куныр бетәләр алар. Үзләре усаллар, үзләре әллә нинди әрсезләр.

— Балабызмы? — ди Фәһимә.

— Кая?

Марат сыбызгысын икенче тапкыр сызгырта.

— Киттек! — ди ул.

— Кая киттек?

— Их, сез, — дигән була Марат, — бернәрсә дә белмисез. Кичә бит бер апа безнең кебекләрне укырга язып йөргән. Без урманда булып калганбыз. Синең пәкең аркасында инде.

— Югалтма үзең кеше пәкесен.

— Кем югалткан? Син юри үзең миңа ябасын бит, беләсең килсә!

— Тиргәшмә, Марат, — ди Оксана. — Ул пәке бит үзе югалды. Әйе бит, Җәмил.

— Үзе...

— Балыйк инде! Әй бу малайлалны!

Без дүртәүләшеп урамга чыгабыз. Арттан Фә-

рит белән Заман куып житә. Алар һаман шулай инде. Балаларның бөтенесеннән соңга калалар.

— Минем дә карандашым бар, — ди Заман, һәм бармак буе гына карандашын Оксанага күрсәтә. — Безнең песи бүген бер тургайны тота язган иде дә, тургай очып китте. Әйбәтме?

— Нәрсә, тургаймы, Заман?

— Карандаш.

Марат Заманга сөйләнмәскә куша. Күп сөйли шул Заман. Әни мине „сөйләргә яратасың", — ди. Заман минем ише генәме соң, бәп-бәләкәй көенә авызы сүздән бушамый.

Без инде урамның теге ягыннан, Хәйбулла Рушаннары ягыннан, йөрергә дә курыкмыйбыз. Рушан хәзер бер дә таш ыргытмый. Яңгыр яуган көнне, безнең бозау тары басуына керергә иткән иде. Без Оксана белән йөгерәбез-йөгерәбез, һич тегене тыеп булмый. Шунда Рушан бозауны тотып бирде. Ул бик шәп йөгерә бит.

Әнә ул әле капкалары башында нәрсәдер җырлап утыра. Кызык малай ул Рушан: я агач ботагына, я өй кыегына, я берәр багана башына менә дә җырлап тик утыра. Үзенең җырын бер аңлап булмый.

— Әйдә, Рушан, мәктәпкә! — ди Марат.

— Мин, сентябрь житкәч, барам, кичә апа шулай диде.

— Ә без улманда йөлдек тә — апаны күлмәдек.

Марат сеңелесенә ачуланып карый:

— Син сакау көенә мәктәптә күп сөйләшеп торма! — ди ул.

Фәһимә үпкәләми, тик үзенең сары башын гына кагып куя:

— Ялал...

Без арткы урамның очына чыктык та мәктәп

янына килеп җиттек. Бер малай да тимәде безгә. Арткы урам малайлары да әйбәтләр бит.

Ишек төбендә без туктап калдык. Берәү дә алдан керми. Фәһимә ишек тоткасына үрелгән иде дә, Марат аның кулыннан тартты. Без тирә-якка карангалап һаман торабыз. Кулына зур кызыл чәчәк тотып, мәктәп бакчасыннан Заман килеп чыкты. Ул башта ук туп-туры шунда йөгергән, ахры.

— Әй күп чәчәкләр таптым, әйдәгез, чәчәк җыябыз,— ди Заман.

Фәрит аны тирги. Бакчадагы чәчәкләрне өзәргә ярыймыни? Бигрәк бернәрсә дә белми шул әле Заман.

— Мин карандашымны югалттым, Фәрит,— ди ул.

Бакчадан бер апа килеп чыга:

— Кайсыгыз монда чәчәк өзеп йөри?

— Мин түгел! — ди Заман, үзе Фәритнең артына поса. Теге апа көлә. Көлгәч, ачуланмыйдыр инде.

— Бакчада уйнарга ярый, тик чәчәкләрне өзәргә ярамый,— ди апа, үзе Заманның башын сыйпый,— өзгәч, бетә бит алар. Барыгыз, уйнагыз.

— Без уйнарга килмәдек, апа, йомыш белән килдек,— ди Марат.

— Йомышыгыз кемдә соң?

— Мәктәптә. Без укылга килдек, апа,— ди Фәһимә. Марат аның итәгеннән тартып куя.

— Юк, әлегә укырга түгел. Безне язып куегыз, апа.

Апа безне мәктәпкә, бер зур бүлмәгә алып керә. Анда балалар утыра торган парталар куелган.

— Я, утырышыгыз, балалар,— ди апа. Без парталар артына керәбез. Апа үзе, өстәл янына

килеп, ниндидер бер китапнымы, дәфтәрнеме ачып куя.

— Апа без кичә урманга бардык...

— Ә-ә, сезмени?

— Без,— ди Заман. Заман дөрес әйтми. Ул кичә урманга бармады.

— Кемнән башлыйбыз?

Без эндәшми торабыз. Шуннан соң апа башта Маратның, аннан Фәритнең, аннан Оксана белән минем исемнәрне, фамилияләрне, яшьләрне сорашты.

Чират Заманга килеп җитте.

Ул апаның янына ук килде дә бая үзе өзгән чәчкәсен сузды:

— Мә, апа. Мин дүрттә.

— Мин алтыда,— диде Фәһимә.

Апа тагын да елмая, үзе Заманның аркасыннан сөя:

— Беләм, беләм. Сезне дә язып куйдым,— ди ул, шуннан соң безгә карый.

— Минем исемем — Рауза апа. Сез бергә-

ләшеп шушы класста укырсыз, мин укытырмын, ә хәзергә барыгыз кайтыгыз, уйнагыз...

Рауза апа безне болдырга кадәр озата чыкты. Без йөгерешеп кайтып киттек. Заман да калышмады.

Чокыр буена җиткәч, без йөгерүдән туктадык.

— Рауза апа әйбәтме?—дип сорады Оксана миннән.

— Әйбәт. Ул безне укырга да, язарга да өйрәтер.

— Тагын ундүрт көннән сентябрь, аны бик белеп торыгыз,—дип әйтеп кайтарды безгә Марат.

Шушы вакыттан алып безне мәктәпкә әзерли башладылар. Әни икебезгә дә матур итеп сумкалар тегеп бирде, әти кибеттән каләмнәр, төрле буяулар алып кайтты. Оксанага да, миңа да яңа күлмәк текteләр.

Без көн саен мәктәп тирәсенә барып кайтабыз; эчкә кермәсәк тә, бакчасында йөрибез. Чәчәкләрне өзмәгәч, безгә берәү дә сүз әйтми. Нинди генә чәчәкләр, нинди генә агачлар үсми ул бакчада!

ЯХШЫ ХӘБӘРЛӘР

Без кичкырын дүртәүләп чәй эчеп утырабыз. Оксана баядан бирле минем белән бәхәсләшә. Мин әйтәм: „1 нче сентябрьгә кадәр җиде көн калды“,—дим. Ул әйтә: „Сигез көн“,—ди. Мин әйтәм: „Юк, җиде“,—дим, ул әйтә „Юк, сигез“,—ди. Әти белән әни эндәшми генә безгә карап торалар.

Сеңелем кинәт әтигә сыена:

— Алайса иң-ин дөресен, әтием, син әйт,—ди ул.

Әти мыегын сыйпап ала, үзе чак кына елмаеп та куя.

— Минемчә,— ди ул,— иң дөресе җиде көн, сигез төн...

Мин бармакларымны бөгеп көннәрне дә, төннәрне дә исәпләп чыкмакчы булам. Тик бер дә рәтен табып булмый. Әй лә, нигә төнне санап торырга. Кешеләр бит төнен йоклыйлар.

Әтием әниемә, аннан безгә күз төшереп ала да тыныч кына сүз башлый:

— Бүген,— ди ул,— ерак җирдән яхшы хәбәрләр алдык, балалар,— бик якын кешебездән хат килде...

Нинди җирләрдән, нинди якын кешедән килде икән ул хәбәрләр? — Әти шуны төшендереп бирми бит. Оксананың чәчләреннән сыйпаганда нигә соң әниемнең кулы чак кына калтыраган-дай итә?

Мин якын кешебез яшәгән ерак җирләр турында уйлыйм. Ул яклар кайда икән? Әллә теге Тимертауның күксел урманы артындамы икән? Мин әтидән шуларны сорашмакчы булам. Ләкин инде әти урыныннан торып китә дә әнием белән сөйләшә башлый: „Көнбикә, син иртәгә умарталыктан бал алып кайтырга онытма. Тимертауга да хәбәр .итәр идең. Шулай әйбәтрәк булыр...“ Әни „ярар“ дип баш кага. Әлбәттә, шулай әйбәтрәк булыр. Дәү әни бездә чакта һәрвакыт әйбәтрәк була. Без дәү әнине дә, балны да яратабыз.

— Ә сезгә, балалар, сүнәй базарына китәргә вакыт,— ди әни. Йоклагыз ди ул шулай. Аның тавышы бүген ни эшләптер тоныклана төшкән.

Ерак җирләр, яхшы хәбәрләр хакында ул кичне бернәрсә дә белә алмыйча, Оксана белән без йокларга яттык.

Ә иртән соң, иртән нәрсәләр генә эшләнмәде безнең өйдә. Без торуга әнием мичне ап-ак итеп агартып куйган, сандыктагы бизәкле тастымаллар кадакларга алып эленгән, зур кроватька безнең теге шакмаклы-шакмаклы матур палас җәелгән. Тәрәзәләргә челтәрле яңа пәрдәләр корылган. Самовар соң, самовар! Нинди ялтырап утыра ул өстәл өстендә.

Әтием бөтен ишек алдын чип-чиста итеп себереп куйган. Саргаеп килгән йорт үләне өстендә энә очы кадәр дә чүп таба алмассың.

Ерак җирләрдән яхшы хәбәрләр килгәч, менә ничек була бит ул!

Кичкә каршы безгә дәү әни дә килеп җитте. Без аны Хәйбулла Рушаннары турысына җиткәч тә күреп каршы йөгереп бардык.

— Дәү әни,— дидек без икебез ике яктан аны кочаклап алып,— безгә ерак җирләрдән яхшы хәбәрләр килде. Шуңа күрә сине дә чакырып җибәрдек...

— Хәбәрнең яхшы булуы әйбәт, балалар...— ди дәү әни, үзе йомшак куллары белән аркабыздан сөя.

Әти көн буе атлары янында йөрде. Менә көтү дә кайтты.

Дәү әни белән Оксана Мансур бабайларга кереп киттеләр. Мин шыпырт кына әнием сыер сауган җиргә бардым.

— Әни,— дидем мин пышылдап кына,— ә, әни, ерак җирдәге якын кеше кем ул?

Әни кинәт миңа борылып карады да йомшак кына тавыш белән әйтеп куйды:

— Изге сәгатькә туры килсә, барысын да үзегез күреп белерсез, улым...

Бер көн үтте, ике көн үтте. Без бернәрсә дә күреп белә алмадык. Ә өченче көнне безнең

өйгә — дәү әни әйтмешли, — сөенеч тә, көенеч тә килеп керде...

КУНАК КИЛДЕ

Көмешле буеннан без кич кенә кайтып кердек. Бакча янындагы бүрәнә өстендә әти белән бер солдат утырып тора. Безне күргәч, теге солдат аягүрә басты да кычкырып ук җибәрде:

— Оксана!.. — ул тагын да нәрсәдер әйтте, тик мин генә аңламадым.

Сеңелем белән без икебез туктап калдык. Оксананы кайдан белә бу мыексыз солдат абый? Әти әйттеме икән әллә?

Мин куркып киттем. Оксана да курыкты. Аның иреннәре калтырый башлады...

— Монда килегез, балалар, бу абый — кадерле кунак, — диде әти. — Ул әле генә килеп төште.

Тик без барыбер кузгалмадык. Кадерле кунак үзе йөгереп килде дә Оксананы күтәреп алды. Башта ул сеңелемнең күзләренә бик озак карап торды, ә аннан соң күкрәгенә кысты. Оксана еламады да, кычкырмады да. Аны бит болай да һәр очраган кеше күтәреп ала. Бөтен кеше ярата минем сеңелемне. Кадерле кунак үзе сөя, үзе сөйләнә: „Оксана... Оксана...“ Мин әтигә карыйм. Ул башын ия дә кул сырты белән күзен уып ала. Чүп кердеме икән әллә аның күзенә? Дәү әни ачык тәрәзәдән тышка карап тора. Ул нигәдер авызын яулык очы белән каплаган. Әни болдырга чыгып баскан. Ул әллә көлә, әллә елый — мин шуны һич аңлый алмыйм. Ул, ахры, елый да, көлә дә.

Ә кадерле кунак Оксананы һаман кочаклап тора. Бу солдатка ачуым да килә башлый, нәрсәседер ошамый аның миңа. Кеше сеңелесен шулкадәр озак сөймиләр инде. Ул кунак минем өчен кадерле дә түгел әле, беләсегез килсә.

Соңыннан кунак кешебез Оксананы җиргә бастыра да мине күтәреп алмакчы була. Мин әти янына качып китәм. Ул кунак тагын бер тапкыр шулай итенсә, сеңелемне Тимертауга алам да таям.

— Алай кырыс итенмә, улым, безнең кунак, Петро абыең, сине ярата бит,— ди әти.

— Кирәкми, яратмасын, мине дә, Оксананы да яратмасын.

Кунак, Оксананы җитәкләп, безнең янга килә. Мин йөгереп китәм дә болдырга барып утырам. Әллә нигә эчем пошып куя. Оксана инде тегенең итәгендә утырып тора... Мин әтигә, әнигә, дәү әнигә карыйм: алар барысы да бүген әллә ниндиләр. Әллә шатланалар, әллә кайгыралар инде. Оксана да бөтенләйгә үзгәреп китте. Минем турыда, ахры, онытты да инде ул... Юк, онытмады. Менә сеңелем минем яныма йөгереп килә. Аның зәңгәр күзләре тагын да яктыра төшкән. Димәк, ул шатлана. Ул куанып кулын чәбәкли

— Беләсеңме, безгә кем килде? — ди.

— Ә кем соң?

— Әйтимме?

— Әйт.

— Безгә килде... Әйтмәсәм, гомергә дә беләчәк түгелсең.

Сез белә алыр идегезме? Мәңге белә алмас идегез.

МЕНӘ КЕМ ИКӘН УЛ БЕЗНЕҢ КАДЕРЛЕ КУНАК

— Көнбикә,— дип чакыра әти,— монда килегез әле. Барыбыз да бергәләп утырып алыйк.

Без шул ук бүрәнәләр өстенә тезелешеп утырабыз. Оксана кунак абый белән минем арага утыра.

Мин Кыр ягына әйләнеп карыйм. Кояш ерак тау артына төшеп бара. Безнең бакча артындагы сыртта атлар яшь курпы ашап йөри. Аларның күләгәләре озын булып җиргә төшә. Ялгызимән төбендә алмачуар ат басып тора. Аның исеме Атака. Ул ат та, этиләр кебек үк, фронтта йөреп кайткан. Атаканың янбашына сугышта пуля тигән. Ул юртканда әле дә чак кына аксап китә. Атака тирәсенә тай-тулак җыелган. Ул акрын гына башын кагып ала, ә тегеләре койрыкларын да кыймылдатмый тик торалар. Бәләкәй атларга Атака сугышта булган хәлләрне, үзенең күргәннәрен сөйли, ахры. Ниләр сөйли икән ул алмачуар ат?

Әти кояшка каршы таш өстенә күчеп утыра. Кояшның кызыл нурлары аның битенә төшә. Әтинең йөзе ялкын бөркеп торган кебек күренә миңа. Аның озын мыеклары дөрләп янып китмәсә ярар иде дип шикләнеп тә куям.

— Кадерле кунакны безнең өйгә нинди язмыш китергәнен сөйләргә вакыт җитте, балалар,— ди әти салмак кына, ул башта Петро абыйга, аннан Оксанага һәм миңа карап ала.

Петро абый башын түбән иеп утыра, нәрсә турындадыр уйлана, ахры, ул. Без Оксана белән икәү әтинең нәрсә әйтүен көтеп торабыз. Ләкин әти сүзен тиз генә башлап китә алмый.

— Минем сүзем кыска булыр,— ди ул, тамагын кырып.— Сугыш ул, балалар,— коточкыч нәрсә. Кешеләргә бик күп кайгы-хәсрәтләр китерә ул. Җимерелгән, яндырылган азмы авыллар һәм шәһәрләр үттек без — әйтеп бетергесез. Безнең дошманнарыбыз — фашистлар ерткычтан да яман булып чыкты. Алар аналарны да, кечкенә балаларны да кызганмадылар.

Без аларны Украина жиреннән куып бара

идек. Бервакыт шулай дошманны Днепр буендагы авылдан бәреп чыгардык. Җимерек хаталар. кара көйгән бакчалар әле дә күз алдымда тора, Бөтен җирне төтен каплаган, хәтта тын алуы да авыр. Урамда кеше заты күренми. Кинәт мин читтәге бер хатада бала елавын ишеттем.

Әти янадан тамак кырды һәм ялт итеп Оксанага карады. Оксана да аннан күзен алмый карап тора. Үзенең иреннәре дә аз гына калтырый. Петро абый, нәрсәдәндер курыккан төсле, бөршәеп кенә утыра. Ул эндәшми генә әтинең сөйләп бетергәнен көтә.

— Мин шул хатага йөгереп кердем. Керсәм — идәндә үлек ана ята. Анын янында бер кыз бала елап утыра. Идән уртасында туктап катып калдым. Нәрсә эшләргә белмим. Ә кулларым ирексездән кыз баланы күтәреп алдылар. Ул миңа кинәт „Әти!“ дип эндәште. Күрәсең, мине шулай ук фронтта йөргән атасы дип уйлады. „Изге сәгатькә, балакай,— дидем мин,— бүгеннән башлап син Җәмилнең туганы булырсың“...

Оксана кычкырып ук җибәрде.

— Ул мин идемме?

— Әйе, син иден, кызым...— диде әти йомшак кына.— Я инде, балалар, калганын тыңлагыз. Мин, мичтән күмер алып, стенага үземнең адресны яздым, шуннан кызымны шинельгә төреп күтәрдем дә иптәшләремне куа киттем... Сугыш тынып торган арада, кызымны якындагы шәһәргә балалар йортына илтеп куярга командирым миңа рөхсәт бирде. „Оксананы килеп ал“,— дип әниегезгә шунда ук хат та яздым. Әниегез ул ерак юлга тик берничә айдан соң гына чыга алды... Туганыңның кайтып төшкән көнен хәтерлисеңдер бит, Җәмил?

Хәтерләми буламы соң?..

— Моннан өч көн элек хат килүе турында әйткән идем сезгә. Ул хатны Петро язган иде. Оксананың атасы — безнең кадерле кунагыбыз һәм туганыбыз Петро бүген үзе килеп төште, — диде эти. Соңгы сүзләрне әйткәндә аның тавышы ничектер калтыранып китте...

Мин кычкырып елап җибәрердәй булдым. Ләкин нәкъ шул вакытта Оксана пышылдап кына миңа эндәште:

— Безнең тагын да бер әниебез бар дигән идем бит сиңа, Җәмил, әйеме... Менә тагын бер этиебез дә килде. Минем этием.

Кинәт Петро абый Оксана белән икебезне берьюлы күтәреп алды да күкрәгенә кысты: Җәмил, Оксана!..“ — дип пышылдады ул.

Шул чакта мин аның чыннан да кадерле кунак икәнлеген аңладым.

СОҢГЫ ӨЧ КӨН

Мин Петро абыйга шунда ук ияләшеп киттем.

Менә дигән кеше ул безнең Петро абый! Оксана белән икебезне ике иңбашына утыртып өй алды буенча күтәреп тә йөри әле ул. Безнең өйдә аннан зуррак кеше дә юк. Чоланга да ул иелеп кенә керә, югыйсә маңгае ишек башына бәрелә. Йомарласа, һәрбер йодрыгы Заманның зур кызыл тубы чаклы булыр. Менә нинди бит ул безнең Петро абый. — Баһадир! — монысын Мансур бабай шулай ди.

Тик дәү әнием генә пошына: „Бигрәк тынгысыз шул. Көн буе ашап-эчеп рәхәтләнеп кунак булып кына ятмаска шунда... Ә аның житмәгән жире юк“, — ди.

Дәү әни дөресен әйтә: бу арада безнең өче-

безнең житмәгән җиребез калмады. Иң башта без Петро абыйга Батырша дәү әти чишмәсен күрсәттек. Аннан якын басуда әниемнәр зур машина белән бодай суккан җиргә бардык. Петро абыем карап торып кына чыдый алмады. Машинаның башына ук менеп барабанга көлтә бирергә тотынды. Оксана белән без читтә эскерт янында басып тордык.

— Солдатның куллары эш сагынган, һай нык сагынган! — ди шунда салам өюче бер бабай.

— Хак! — дип аның сүзен куәтли апа кеше.

Машина туктаган арада тузанга батып беткән Петро абый безнең янга килде. Шуннан соң без өчәүләп әтиемнең атлары янына барып чыктык. Их, шәп тә соң безнең атлар. Алар Петро абыйга да бик ошады.

Әйтәм бит, йөрмәгән җиребез калмады — яшелчә бакчасында да, умарталыкта да, кирпеч суга торган җирдә дә булдык без. Петро абыйга безнең авыл бик ошады, ахры, — күреп туя алмый. Ә кешеләр соң, кешеләр! Һәрберсе Петро абыйга „Хуш килдең, туган!“ — дип эндәшә һәм аның кулларын кысып, озак-озак итеп күрешә. Карт әбиләр аның аркасыннан сөеп алалар. Ка-

дерле кунак булмаса, кешеләр шулай яратырлар идеме соң Петро абыйны, ә?..

Петро абыйга иң ошаган нәрсә — безнең тимерлек булды. Без анда әллә ничә тапкыр бардык. Тимерлектә ике Габи эшли — берсен Юан Габи, икенчесен Нечкә Габи дип йөртәләр. Габиләр кадерле кунак белән тиз үк дуслашып алдылар. Сөйләшеп сүзләре бетми. Барган саен Петро абый, җиңнәрен сызганып, кулына чүкеч ала. Берчак ул минем баш кадәрле чүкечне күтәреп кызган тимер өстенә китереп суккан иде, теге тимер коймак калынлыгы гына калды.

— Менә тимерче, ичмасам,— ди Нечкә Габи Юан Габигә.— Менә кемдә ул көч!

Шушы тимерлектә инде Петро абый мина тимер саплы пәке, әниемә кисәү агачы ясап бирде. Тик Оксанага гына бер әйбер дә булмады. Курчак ясап булмый шул монда...

Әнием әйткәндәй, төштәге кебек үтте дә китте ул өч көн.

СЕРЛЕ СӨЙЛӘШҮ

Оксана белән Петро абый өйгә кереп киттеләр. Мин тимерлектән алып кайткан әйбәт нәрсәләремне теге таш сарайга куярга дип бакчага кердем. Яз утырткан алмагачлар арасыннан иелеп кенә мин каен төбенә килдем. Менә Оксана алмагачы, менә минеке. Әнә алары әтием белән әниемнеке... Ә бу читтәгесе кемнеке соң? Теге чак, яз көне, әни нәрсә әйткән иде әле? „Бишенче алмагач кунакка булыр“,— дигән иде. Безнең хәзер кадерле кунагыбыз бар. Шулай булгач, бишенче алмагачны Петро абыйга атыйм да куям. Нинди әйбәт булып чыкты.

Кесәдәге тимер-томырларны бушатып торганда

мин бакчаның аргы башында кемнәрнеңдер мыгыр-мыгыр сөйләшкәнен ишетеп калдым. „Кемнәр икән?“ Мин кинәт әйләнеп карадым. Киртәнең бу ягына дәү әни баскан, теге яктан Мансур бабайның ак сакалы җилфердәп күренеп тора.

— Бигрәк бала җанлы инде. Үзе шундый кечелекле, үзе харап уңганга охшап тора,— ди дәү әни.— Уңдык яңа туганнан, бик уңдык.

— Шулай, шулай, карендәш,— дип Мансур бабай аның сүзен куәтли,— кешеләрне тел дә, байлык та туганлаштырмый. Кешеләрне йөрәк туганлаштыра. Мин күп яшәгән кеше инде, беләм: бу заман кешеләрнең тормышларын гына түгел, йөрәкләрен дә яхшыртты.

Дәү әни көрсенеп куя да янадан сөйли башлый:

— Йөрәк итен телеп алган кебек булыр инде, Мансур абзый. Артык нык ияләштек шул кызыбызга. Атасын да әле күреп туя алган юк. Җәмил белән Көнбикә бигрәк өзгәләнер инде. Шушында бергәләп кенә яшәүгә ни җитәр иде дә бит, күндереп булмый шул.

Аннан соң Мансур бабайның калын тавышы ишетелә:

— Күндерергә кирәкми дә, карендәш. Үз җире көл-күмергә калган ир егет, йөрәге чыдап, монда ятмас шул. Аның урынында булсам, мин дә үз туфрагыма кайтып орлык чәчәр идем...

Бу ике олы кешенең сөйләшүе бик серле тоелды миңа. Эчемдә нәрсәдер келт итеп өзелгәндәй булды. Әйе, алар сеңелем белән Петро абый турында сөйлиләр иде.

Мин атлыгып өйгә кердем. Сеңелем аякларын селкеп сандык өстендә утыра, үзе атасына нәрсәдер сөйли. Аның ачык зәңгәр күзләре ничек елмаялар!.. Мин шунда ук тынычланам. Юк ла, алар беркая да китмәгәннәр бит!

— Син хәзинә сараена бардың, мин беләм инде,—ди сеңелем.— Әйдә синең атыңа утырып минем курчакларымны кунакка алып китәбез.

— Ә кая?

— Еракка. Би-и-к — еракка, Украинага.

Йөгерә-атлый дәү әни килеп керә һәм шунда ук самоварына тотына, үзе сөйләнә:

— Кунаклар кайтып та җиткән, ә мин күрми дә калганмын. Менә ничек була бит ул, дөньяны онытып йөргәч. Я инде!..

Ә минем колак төбемдә башка сүзләр яңгырый. „Йөрәк итен телеп алган кебек булыр инде...“ Нигә шулай ди икән ул?

Нигә икәнен мин тик соңыннан гына аңладым.

ОЗАТУ

Август аеның соңгы көне килеп җитте. Ул иртә шундый җылы иде. Өй алдындагы сары үләннәр, бакчадагы агач яфраклары, өй түбәләре, урамдагы яңа телеграф баганалары — барысы да, барысы да кояш нурына күмелгән.

— Җәй безнең белән ничек җылы һәм ягымлы итеп хушлаша!— ди дәү әни.— Без аны яхшы сүз белән хәтергә алырбыз.

Бу иртәдә Петро абый һәм Оксана безнең авыл белән саубуллаштылар.

Капка төбендә күптән инде җигүле Атака тора. Арба тирәсендә малайлар һәм кызлар йөгерешеп йөри. Зурлар койма буенда сөйләшеп тора.

Өйдә юлга җыеналар. Әни Оксанага иң матур күлмәген кидерә. Петро абый тиз генә кырынып ала. Аның мыегы зур түгел бит, шуның өчен тиз.

Әти юл әйберләрен арбага чыгарып сала да яңадан өйгә керә. Дәү әни барыбызга да чак

кына утырып торырга куша. Тик шул вакытта гына әни, миңа табан борылып, әйтеп куя:

— Менә, Җәмил,— ди ул,— сеңелең белән хушлашыр вакыт та җитте. Бүген Оксана атасы белән бергә Украинага китә. Соңыннан без дә җыелып Петро абыеңнарга кунакка барырбыз. Ярармы, кызым?— ул бу сүзләрне Оксанага әйтә.

— Әй, әнекәем, тизрәк килегез,— ди сеңелем.— Ә Җәмил әле үк барсын. Барасыңмы, Җәмил?

— Икегез дә киткәч, өйдә кем калыр соң? Җәмил безнең белән барыр,— ди дәү әни.

Мин аптырыйм: ни эшләп Оксана үзе генә китә икән? Мин бит аның белән теләсә кая барырга әзер торамын. Шуны аңламыйлармы икәнни?

Азрак утырганнан соң, дәү әни урыныннан тора. Аның артыннан без дә кузгалабыз.

Барыбыз да урамга чыгабыз. Кешеләр Петро абыйны уратып алалар, аның кулларын кысалар:

— Сау бул, туган,— диләр алар,— безне онытма. Кунакка ешрак кил.

Кемдер Оксананы күтәреп алып, битләреннән үбә. Шуннан соң, аны кулдан-кулга йөртәләр. Саубуллашу бик озакка сузыла. Сеңелем янына иң азактан дәү әни килә һәм аның чәчләреннән сыйпый.

— Бәхетле, тәүфыйклы бул, кызым,— ди. Дәү әнинең яшьле күзләре бер ачыла, бер йомыла.

Без бишебез дә арбага менеп утырабыз. Әни Оксананы итәгенә ала. Әти дилбегәне селтәп җибәрә. Без кузгалып китәбез. Капка төбенә җыелган кешеләр карап калалар. Фәһимә кычкырып еларга тотына, ә Марат белән Фәрит арба артыннан ияреп йөгереп килә.

— Сау бул, Оксана!— ди Марат.

— Исән бул!— ди Фәрит.

Сеңелем малайларга кул болгый. Урам башында алар да туктап калалар.

Теге чакта без әти белән туктап хәл җыйган урманлы тауны да үтеп китәбез. Тугайга килеп чыккач, әти атны туктата. Иң элек арбадан үзе сикереп төшә.

— Барыгыз, балалар, сез алдан йөгерегез, арыгач тагын утырырсыз,— ди ул.

Әни Оксананы арбадан төшерә, ә мин үзем сикереп төшәм. Без саргая башлаган үлән өстеннән йөгереп китәбез. Монда инде чәчәкләр дә юк, алар коелып беткәннәр, күбәләкләр дә әллә кая очып киткәннәр. Зур печән эскертенең башында бер зур соры кош утырып тора. Җиргә аның кара күләгәсе төшә. Мин „кош-еш!“ дип кычкырам, ул барыбер очып китми.

— Куркытма, Җәмил, я аның йокысы киләдер. Нигә ул ялгыз икән? Аның балалары кайда икән? — ди Оксана.— Әллә кунакка киттеме икән?—Ул кинәт тынып кала. Азрак баргач акрын гына сөйли башлый:—Әни бүген иртән мине чоланга алып чыгып сөйде-сөйде дә кычкырып еларга тотынды...

Мин артка әйләнеп карыйм. Әти, әни, Петро абый өчесе дә арба артыннан атлап килә.

Еракта безнең Кыр ягы чак кына күренеп тора. Җәй көне анда, минем сеңелемнең күзләре төсле, зәңгәр чәчкәләр — күгәрчен күзләре үсә. Без аларны җыеп кайтып, сулы стаканга утыртып куя идек. Ә хәзер ул чәчәкләр дә юк инде. Безнең яңа башмакларыбыз да искерде. Оксана да китә. Өйдә бары „Оксана“ исемле каз бәпкәсе белән „Оксана“ исемле алмагач кына калды.

— Син китмә, туганым,— дим мин.

— Әни дә барырга куша бит,— ди ул.— Минем әтием бик әйбәт. Ул сине дә, мине дә ярата.

Ә син әниләр белән бергә безгә кунакка килерсең. Безнең анда яңа өебез булыр.

Әтиләр атны чаптырып, безнең арттан килеп җитә. Оксана белән без арбага менеп утырабыз. Без бик озак барабыз, зур урманнарны, күл буйларын, күперләрне үтәбез. Шуннан соң тагын тауга менәбез. Безнең алдан, озын төтен чыгарып, поезд үтеп китә. Еракта, агачлар арасында, бер ак йорт күренеп кала.

— Менә килеп тә җиттек,— ди әти.

Без әнә шул ак йортка җитәр-җитмәс бер агач төбендә туктыйбыз. Әти белән Петро абый йортка кереп китә, без өчәү арбада утырып калабыз. Азрак торгач, әни безне теге йорт янына алып килә. Шушы йортның янында гына дүрт озын тимер юл ялтырап ята. Аларның очы да, кырые да күренми. Шушы тимерләр өстеннән тәгәрәп китә инде поездның тәгәрмәчләре.

Йорт тирәсенә, Мансур бабайларның балта чары төсле зур-зур ташлар җәелгән. Шул ташлар өстенә басып, кешеләр йөреп тора. Барысы да зурлар, безнең кебекләр берәү дә юк.

Әни безне җитәкләп ала, һәм без өчәүләп шушы ташларга басып йөрергә тотынабыз. Әни үзе көлми дә, сөйләшми дә.

— Билетлар булды!— дигәнне ишетеп, без әйләнеп карыйбыз. Әти белән Петро абый безнең артта басып тора.

— Тиздән поезд киләчәк, мин әйберләрне китерим,— ди дә әти кызу-кызу атлап китеп бара. Без дүртәү шунда калабыз. Петро абый белән әни нәрсәдер сөйләшә. Русча белмәгәч, мин аларның сүзен аңламыйм.

Әйберләрне күтәреп, әти дә килеп җитә. Инде алар өчәүләп сөйләшә башлыйлар.

— Килә!— дип кычкырды кемдер.

Ишек алдындагы халык арлы-бирле йөгергәли башлады. Агачлар артыннан ухылдап паровоз килеп чыкты. Шул вакыт җир тетрәп куйгандай булды. Ул пых-пых килеп безнең яннан узганда мин куркып та киттем. Шуннан соң әкрен генә яшел вагоннар үтә башладылар. Әни мине кинәт җитәкләп алды. Без вагоннар артыннан йөгердек. Бер вагон янында Петро абый туктап калды. Без дә шунда килдек. Киеменә ялтырап торган төймәләр тезелгән бер кешегә Петро абый билетын сузды.

Без саубуллаша башладык. Петро абый башта әтине нык итеп кочаклады, аннан соң әнинең кулларын кысты, иң азактан мине күтәреп алды да өч тапкыр битемнән үпте.

Оксана кинәт әнигә килеп сыенды. Әни аны кысып-кысып кочакларга тотынды. Шуннан әтием сеңелемне әни кулыннан тиз генә алып сөйде дә җиргә төшерде.

— Саубуллашыгыз инде, балалар,— диде әти.

Сеңелем миңа әйләнеп карады. Аның яңаклары буйлап юл-юл булып яшь ага иде.

Мин сеңелемнең беләгеннән тотып алдым:

— Оксана, китмә, туганым!

— Җәмил, елама, улым, сез тиздән тагын күрешерсез. Без бит бер үк туган илдә яшибез,— диде әти.

Петро абый сеңелемне тиз генә вагонның өске баскычына бастырып куйды, шуннан соң үзе сикереп менде.

Паровоз кычкыртып җибәрде. Вагоннар кузгалып китте. Без кул болгап калдык. Менә Оксана вагон тәрәзәсеннән үрелеп карады. Ул нәрсәдер кычкырды ахры, тик мин генә ишетмәдем...

Поезд урман эченә кереп югалды. Ә без һа-

ман шунда басып торабыз. Кинәт мин әнинең йомшак тавышын ишетәм:

— Үз оясына очып китте... Кошчыгым минем... Шатлыгым минем...

Әти бик озак уйланып тора. Аннан соң беребезгә дә карамый сүз башлый:

— Алай димә, Көнбикә. Кызыбыз гомер буе безнең өебезнең яме булып калыр. Хәзер Оксананың гына түгел, безнең барыбызның да ике оябыз булачак. Үз нигезендә Петро өр-яңа зур йорт салыр. Ул булдыклы, куәтле кеше. Моннан соң шатлыклар да, кайгылар да алар белән уртак булачак... Бер-беребезгә кунакка йөрешербез, кирәк чагында ярдәм дә итешербез.

Мин һаман да урман өстенә сибелеп калган төтенгә карыйм. Бу — Оксананы алып киткән паровоз төтене.

... Менә минем күз алдыма Петро абый үзе салган яңа йорт килеп баса. Йорт алдында безнеке кебек үк бакча, анда бер каен, биш алмагач үсеп утыра. Ишек алдында ап-ак казлар йөри. Без Оксана белән җитәкләшеп биек болдырга менеп барабыз...

Еракта паровоз кычкырта. Мин башымны күтәрәм. Минем баш очымда аяз күк йөзе, сеңелем Оксананың күзләре төсле, ачык зәңгәр күк йөзе.

Оксана... Сеңелем, безнең өйнең яме син...



ЭЧТӘЛЕК

Әнием кая китте? 3
Батырның кылычы кайда? 5
Танып булмый торган язу 11
Менә кем икән минем сеңелем 15
Оксана курка 21
Сеңелемнең төше 26
Усал ата каз 29
Жиңү алмагачлары 32
Чуклы башмаклар 40
Акты да китте бер башмак 46
Мин чын флаг тотып барам 58
Безнең әтине күрмәдегезме? 66
Төш тә, өн дә 71
Без тиздән мәктәпкә барачакбыз 81
Яхшы хәбәрләр 87
Кунак килде 90
Менә кем икән ул безнең кунак 91
Соңгы өч көн 94
Серле сөйләшү 96
Озату 98

М. КАРИМ

РАДОСТЬ НАШЕГО ДОМА

(на татарском языке)

Техник редакторы *Ф. Г. Нурутдинов*

Художество редакторы *Б. М. Альменев*

Корректоры *С. В. Насыйбуллина*

Наборга бирелде 29/XII-1953 ел. Басарга кул куелды 22|IV-1954 ел. ПФ 01191.
Кәгазь форматы $84 \times 108^1/_{32}$. Учет-изд. 4,18 таб. Басма табак 6,5 (5,33).
Табакта 44.000 хәреф. Заказ № 0445. Тираж 10.000. Бәясе 2 сум 45 тиен.

ТАССР Министрлар Советы янындагы Полиграфия промышленносте, издательстволар һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Татполиграф типографиясе.
Казан, Миславский ур., йорт 9.

Бэясе 2 сум 45 тиен